**Кереш......................................................................................................60**

**Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау..................................61**

**Хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә кеше хокукларын яклау.........67**

**Гражданнарның торакка хокукларын яклау....................................72**

**Социаль әһәмиятле учреждениеләрне үзгәртеп кору шартларында кешенең сәламәтлек саклау һәм медицина ярдәменә, белемгә, социаль хезмәт күрсәтүгә хокукларын яклау.......................................................................................79**

**Инвалидларның хокукларын яклау..................................................85**

**Хәрби хезмәткә чакырылучылар һәм чакырылыш буенча хәрби хезмәткәрләр хокукларын яклау.........................................................91**

**Миграция мөнәсәбәтләре өлкәсендә кеше хокукларын яклау......94**

**Пенитенциар система учреждениеләрендә тотылучы затлар хокукларын яклау.......................................................................................99**

**Йомгак......................................................................................................104**

# Кереш

Татарстан Республикасында кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен саклау турындагы әлеге доклад “Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында”гы 95 нче, 2000 елның 3 мартында чыккан Татарстан Республикасы Законының 26 маддәсенә ярашлы рәвештә әзерләнде һәм Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы Конституция судына, Татарстан Республикасы Югары судына, Татарстан Республикасы Арбитраж судына, Татарстан Республикасы прокурорына җибәрелә.

Әзерләнгән доклад Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә (алга таба - Вәкилгә) килгән шикаятьләрне карау нәтиҗәләренә, тикшерү йомгакларына, “Халык контроле” дәүләт мәгълүмат системасы белешмәләренә, дәүләт органнары һәм җирле үзидарәләр органнары мәгълүматларына, шулай ук Вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләре биргән мәгълүматларга, хөкүмәтнеке булмаган хокук саклау оешмалары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белдерүләренә, республика ведомствоара комиссияләре материалларына һәм башка чыганакларга нигезләнә.

Югарыда күрсәтелгән материаллар нигезендә докладта тормышның мөһим өлкәләрендә - хезмәткә, торакка, сәламәтлек саклауга һәм медицина ярдәменә, социаль хезмәт күрсәтүгә, белемгә кеше хокукларын саклау белән бәйле хәл анализланды.

Докладта шулай ук инвалидларның, хәрби хезмәткә чакырылган хәрбиләрнең, мигрантларның һәм мәҗбүри тоту урыннарында тотылучы затларның хокукларын тәэмин итү һәм саклау буенча аерым очракларга бәя бирелә.

## Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау

Гражданнарның мөрәҗәгатьләре шактый дәрәҗәдә Докладның эчтәлеген тәшкил итә. 2017 елда Вәкаләтле вәкилгә 3985 мөрәҗәгать керде, бу 2016 елгы мөрәҗәгатьләр белән чагыштырганда 13,3 процентка күбрәк (былтыр – 3549 мөрәҗәгать).

### 2017 елда Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә килгән мөрәҗәгатьләр саны

| Күрсәткечләр | Гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләр саны |
| --- | --- |
| Барлык мөрәҗәгатьләр | 3985 |
| Телдән мөрәҗәгатьләр | 1850 |
| Язмача һәм электрон рәвештә килгән мөрәҗәгатьләр | 2135 |

Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына килгән шикаятьләр киң кырлы. Иң күп мөрәҗәгатьләр гражданнарның торакка хокукларын тормышка ашыруга, шул исәптән, социаль ипотека программасы һәм социаль найм килешүләре буенча торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар сыйфатында гражданнарны исәпкә алуга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны һәм ятимнәрне махсуслашкан торак белән тәэмин итүгә, күпквартирлы йортлар төзү өчен акча биргән гражданнар хокукларын бозуга, социаль ипотека программасы буенча төзелгән кайбер йортларның түбән сыйфатлы булуына, кулланучыларга торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү сыйфатына кагыла. 2017 елда әлеге темага 793 мөрәҗәгать килде.

Шулай ук Татарстан Республикасы гражданнарын социаль тәэмин итү һәм социаль яклау мәсьәләләренә кагылган (462 мөрәҗәгать), суд карарлары белән риза булмау турындагы мөрәҗәгатьләр (300 мөрәҗәгать), хокук саклау органнары хезмәткәрләренә шикаятьләр (271 мөрәҗәгать) һәм иректән мәхрүм

итү урыннарында тоту шартларыннан зарланган мөрәҗәгатьләр дә күп. (197 мөрәҗәгать).

2017 елда Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә килгән мөрәҗәгатьләрнең җентекле темалары 1 нче Таблицада күрсәтелгән (2016 ел белән чагыштырып бирелә).

*Таблица 1*

**2017 елда Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә килгән мөрәҗәгатьләр темалары структурасы**

| Мөрәҗәгатьләр темасы | 2016 ел | | 2017 ел | |
|---|---|---|---|---|
| | саны | % | саны | % |
| Торак мәсьәләләре, шул исәптән, торак-коммуналь хезмәт күрсәтү | 651 | 21,15 | 793 | 19,90 |
| Суд карарлары белән риза булмау | 247 | 7,04 | 300 | 7,53 |
| Хокук саклау органнары хезмәткәрләренә шикаятьләр | 334 | 8,51 | 271 | 6,80 |
| Халыкны социаль тәэмин итү һәм социаль яклау | 427 | 10,17 | 462 | 11,59 |
| Тоткыннарны мәҗбүри тоту урыннарында яшәтү шартлары | 287 | 5,57 | 197 | 4,94 |
| Хезмәт законнары | 272 | 5,54 | 152 | 3,81 |
| РФ Кораллы Көчләрендә хезмәт итү | 51 | 3,04 | 74 | 1,86 |
| Медицина хезмәте күрсәтү | 156 | 7,41 | 215 | 5,40 |
| Мәгариф | 37 | 1,23 | 205 | 5,14 |
| Җир мәсьәләләре | 66 | 1,93 | 88 | 2,21 |
| РФ гражданлыгы кабул итү һәм паспорт бирү мәсьәләләре | 122 | 2,7 | 99 | 2,48 |
| Башкару производствосы | 99 | 1,77 | 87 | 2,18 |
| Хокукый мәгълүмат бирү мәсьәләләре | 146 | 6,2 | 256 | 6,42 |
| “Халык контроле” системасы эшенә кагылышлы мәсьәләләр | 364 | 6,67 | 442 | 11,09 |
| Башка мәсьәләләр | 290 | 11,07 | 344 | 8,63 |
| Барлыгы: | 3549 | 100 | 3985 | 100 |

2017 елда карарларында яки эшләрендә (эшләмәүләрендә) кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре бозылу булган дәүләт органнары, җирле үзидарәләр органнары һәм вазифадагы затларга хокукларны һәм ирекләрне кире торгызу өчен кирәкле һәм тиешле чаралар күрүне сораган Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Заключениеләре күбрәк торак һәм хезмәт хокукларын бозу уңаеннан җибәрелде.

Кайбер мөрәҗәгатьләрне Вәкаләтле вәкил эшче киңәшмәләр, “түгәрәк өстәл”ләр, Вәкаләтле вәкил каршындагы Эксперт Советы утырышлары үткәрү юлы белән коллегиаль төстә карады.

Россия Федерациясе территориясендә гражданлыгы булмаган килеш яшәүче затларның хокукый статусын көйләү өлкәсендә килеп туган хәл уңаеннан, теге яки бу илнең гражданлыгы булмаганлыктан һәм туган иленә кайту өчен таныклык алу мөмкинлеге булмаганлыктан, әлеге төр гражданнарны илдән чыгарып җибәрү мөмкин булмау белән бәйле мәсьәләләр буенча 2017 елның апрелендә Вәкаләтле вәкил каршындагы Эксперт Советы утырышы үткәрелде.

Эксперт Советы йомгаклары буенча федераль башкарма хакимияте органнары адресына гражсансызлык статусын билгеләүнең аерым тәртибен кертүгә һәм тиешле документлар белән, гамәлдән чыгарылмаган суд карары булган гражданлыгы булмаган затларга гражданлыгы булмаган зат статусы кертүгә, илдән чыгарылырга тиешле чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны вакытлыча тоту махсус учреждениеләрендә булуның конкрет срокларын билгеләүгә кагылышлы кабул ителгән карарлар турында конкрет тәкъдимнәр белән мәгълүмат җибәрелде.

Сәламәтлекне саклауга һәм медицина ярдәменә гражданнар хокукларын яклау, сирәк (орфан) авырулар белән авыручы гражданнарны дарулар белән тәэмин итү, медико-социаль экспертиза, техник тернәкләндерү чаралары һәм санатор-курорт путевкалар белән тәэмин итү мәсьәләләре, 2017 елның июнендә Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил үткәргән Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Т.Н.Москалькова катнашындагы Россия Федерациясе Идел буе

округы субъектларында кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр Координацион советы утырышында карау предметы булды.

Техник тернәкләндерү чаралары белән тәэмин итү (сатып алу срокларын кыскарту, алдан сатып алу процедураларын финанслау лимитыннан башка тормышка ашыру, техник тернәкләндерү чараларын мөстәкыйль төстә алган өчен компенсация түләү тәртибен камилләштерү); мөстәкыйль төстә алынган санатор-курорт путевкасы өчен акчалата компенсация алу, сирәк (орфан) авырулар белән авыручы затларны федераль бюджетның финанс чаралары исәбенә үзәкләштерелгән сатып алына торган дару препаратлары исемлеген киңәйтүгә кагылышлы тәкъдимнәр булган Координацион совет карары утырыш йомгаклары буенча кабул ителгән йомгаклау документы булып тора, ул Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә җибәрелде.

Вәкаләтле вәкил Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасындагы тикшерү идарәсе җитәкчесе урынбасары белән берлектә, Россия Эчке эшләр министрлыгының Түбән Кама муниципаль районы буенча идарәсенең вакытлыча тоту изоляторы камерасында тотылган гражданның үз-үзенә кул салуы сәбәпле, 2017 елның октябрендә гражданнарны мәҗбүри тоту урыннарында тоту шартларына кагылышлы мәсьәләләр буенча 36 гражданны кабул итте.

Шулай ук республиканың банк өлкәсендә кризис булу һәм “Татфондбанк” һәм “Интехбанк” оешмалары эшен туктату сәбәпле, Татарстан Республикасы Эчке эшләр министры белән тематик кабул итү оештырылды, анда гражданнар акчаларын кире кайтару һәм кертемнәрне теркәгәндә “Татфондбанк” хезмәткәрләре ягыннан алдау фактлары буенча чаралар күрүне сорап мөрәҗәгать иттеләр.

2017 елда барлыгы 10 гражданнарны тематик уртак кабул итү булды. Әлеге кабул итүләр Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасындагы идарәсе, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы җитәкчелеге белән берлектә Түбән Кама,

Азнакай, Яшел Үзән, Чистай, Лениногорск муниципаль районнарында, Казан һәм Чаллы шәһәрләрендә үткәрелде.

2017 елда шулай ук Россия Федерациясе Президентының Татарстан Республикасындагы кабул итү бүлмәсендә гражданнарны бердәм кабул итү көннәрендә Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратында 30 шәхси кабул итү; видеоконференцэлемтә режимында шәхси кабул итү; Татарстан Республикасының Лениногорск, Әлки, Әлмәт, Менделеев, Яңа Чишмә муниципаль районнарында урынга чыгып 5 тапкыр кабул итү; Казан шәһәрендә Татарстан Республикасы экс-прокуроры К.Ф.Әмиров белән бергә кабул итү үткәрелде.

2017 елның июнендә Казан шәһәрендә Татарстан Республикасында беренче тапкыр Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән бергә уртак кабул итү үткәрде.

Әлеге кабул итү кысаларында гражданнар федераль Вәкаләтле вәкилгә алдан тикшерүне объектив булмаганча алып бару шикаяте һәм җинаять эше буенча карауны яңарту үтенече белән, сирәк (орфан) авыру белән авыручы йөкле хатын-кызны дару препараты белән тәэмин итү, федераль законга үзгәрешләр кертү юлы белән беренче төркем инвалидка баланы уллыкка алырга булышлык итү, элеккеге ирен ата-ана хокукыннан мәхрүм итүдән баш тарткан суд карары белән килешмәү мәсьәләләре буенча мөрәҗәгать итте.

2017 елда “Россия пенсионерлары берлеге”нең Татарстандагы бүлеге белән берлектә пенсионерлар һәм республиканың башка социаль яктан якланмаган төркемнәре өчен 8 “Хокукый ярдәм көне” үткәрелде, алар кысаларында 429 кешегә консультация бирелде, шулай ук Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе белән берлектә төзәтү учреждениеләрендә 9 “Хокукый ярдәм көне” үткәрелде. Аларда 355 кешегә, шул исәптән Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил үзе 84 кешегә консультация бирде.

Халыкка торакка хокук һәм торак-коммуналь хуҗалыгы мәсьәләләре буенча уңайлы һәм бушлай юридик ярдәм күрсәтү һәм гражданнарны хокукый агарту максатыннан «Торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсендә җәмәгатьчелек контроле төбәк үзәге» коммерциячел булмаган партнерлыгы, «Татарстан Республикасында күп фатирлы йортлар идарәчеләре оешмалары берлеге» төбәк коммерциячел булмаган партнерлыгы» үзкөйләүле оешмасы белән берлектә идарәче оешмалар катнашында күрсәтелгән тематика буенча "Хокукый ярдәм көннәре" үткәрү практикасы кертелде. 2017 елның икенче яртыеллыгында торак-коммуналь хуҗалыгы мәсьәләләре буенча 5 "Хокукый ярдәм көне" үткәрелде, аларда 1100 кеше булды, 90 кешегә шәхси консультация бирелде.

Татарстан Дәүләт Советының "Мәрхәмәт-Милосердие" хатын-кыз депутатлар берләшмәсе белән берлектә 2017 елда туучылар санын арттыру буенча чаралар турында, балаларны гомум белем бирү учреждениеләренә урнаштыру, балалар һәм үсмерләрнең җәйге ялын оештыру мәсьәләләре буенча 2 "кайнар элемтә" үткәрелде, аларда 200 кеше мөрәҗәгать итте.

2017 елның сентябрендә Вәкаләтле вәкил Социаль иминият фондының Татарстан Республикасындагы дәүләт төбәк бүлеге һәм "Медико-социаль экспертиза баш бюросы" җитәкчелеге белән берлектә инвалидлар хокукларын яклау, шул исәптән сыйфатлы техник тернәкләндерү чаралары белән вакытында тәэмин итү мәсьәләләренә кагылышлы "кайнар элемтә" оештырды, анда 94 кеше шалтыратты.

Республиканың барлык муниципаль район һәм шәһәр округларында Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләре җитәкли торган җәмәгатьчелекне кабул итү бүлмәләре эшли.

2017 елда җәмәгать ярдәмчеләренә 1798 граждан мөрәҗәгать итте. Җәмәгать ярдәмчеләренә гражданнар мөрәҗәгать итә торган төп сораулар – беренче чиратта торак, шулай ук торак-коммуналь хезмәт күрсәтү, социаль яклау һәм социаль тәэмин итү, медицина хезмәте күрсәтү, хезмәт законнары, җир һәм мәгариф мәсьәләләре бар.

Вәкаләтле вәкил “Халык контроле” дәүләт мәгълүмат системасының баш модераторы буларак 2017 елда килгән мөрәҗәгатьләрне карау һәм мөрәҗәгатьләрне сыйфатлы карау, мөрәҗәгатьләргә статуслар бирүнең нигезлелеге буенча җаваплы башкаручылар кабул итә торган чаралар мониторингы буенча эшне дәвам итте.

2017 елда “Халык контроле” дәүләт мәгълүмат системасында барлык статуслардан эшкә кайтарылган мөрәҗәгатьләрне исәпкә алып, 50363 мөрәҗәгать урнаштырылды, бу узган ел белән чагыштырганда 16 процентка күбрәк.( Былтыр - 43387 гариза).

2017 елда системадан кулланучылар иң күп мөрәҗәгатьне “Территорияләрне төзекләндерү” төре буенча - 24866 мөрәҗәгать, “Муниципаль юлларны карау һәм төзекләндерү” төре буенча - 14177 мөрәҗәгать, “Юл хәрәкәтен оештыру” төре буенча - 6476 мөрәҗәгать, “Торак-коммуналь хезмәт күрсәтү” төре буенча - 5251 мөрәҗәгать, “Сату кагыйдәләрен бозу” төре буенча - 2240 мөрәҗәгать, “Тышкы рекламада хокук бозулар” төре буенча - 2788 мөрәҗәгать җибәрде.

2017 елда барлыгы эшләү өчен 3162 мөрәҗәгать кире кайтарылды, иң күп кире кайтарылган төрләр – “Муниципаль юлларны карау һәм төзекләндерү” – 885 мөрәҗәгать; “Территорияләрне төзекләндерү” – 720 мөрәҗәгать; “Юл хәрәкәтен оештыру” – 669 мөрәҗәгать.

Ел дәвамында “Халык контроле” дәүләт мәгълүмат системасына килгән гражданнар мөрәҗәгатьләрен күзәтү кысаларында ачыкланган кайбер проблемалы мәсьәләләр шулай ук доклад эчтәлегендә чагылыш тапты.

## Хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә кеше хокукларын яклау

Россия Федерациясе Конституциясе һәр граждан үзенең хезмәткә хокукларын ирекле төстә кулланырга, эшчәнлеге төрен һәм һөнәр сайларга хокуклы булуын белдерә. Шул ук вакытта хезмәте өчен гарантияләнгән һәм үзвакытында түләү алу һәр хезмәткәрнең аерылгысыз хокукы булып тора.

Компетентлы күзәтчелек органнары гына түгел, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарәләр органнары тарафыннан да эш хакы буенча бурычны бетерү буенча системалы эш алып барылса да, хезмәт хакын законда каралган вакытта түләмәү кискен булып кала бирә.

Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы рәсми мәгълүматлары буенча авыл хуҗалыгы, ау, агач әзерләү, эшкәртүче җитештерү, төзелеш предприятиеләре һәм оешмаларының 2018 елның 1 гыйнварына 10,2 миллион сум бурычы бар. Әлеге күрсәткеч буенча узган еллар белән чагыштырганда әлләни зур үзгәреш юк. Шул ук вакытта дүрт ай буе (2017 елның июленнән ноябрьгә кадәр) эш хакы буенча бурыч даими арту үзенә игътибарны җәлеп итә. Бу чорда бурыч 5,916 миллион сумнан 12,444 миллион сумга кадәр артты.

Судка мөрәҗәгать итү гражданнарның хезмәткә хокукларын яклауның киң таралган ысулларыннан берсе. Үз чиратында Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе мәгълүматлары бурычлының мөлкәте булмау сәбәпле эшкә түләү бурычын алу буенча башкару эшләре саны сизелерлек артуын дәлилли. 2017 елда андый башкару эшләре 146 булган (фактта үтәү белән төгәлләнгән эшләрнең гомуми саныннан 3,18 процент), ә 2016 елда бу сан 28 (фактта үтәү белән төгәлләнгән эшләрнең гомуми саныннан 0,37 процент). Шуның белән бергә, узган чор йомгаклары буенча бурычлы оешманы банкрот дип тану һәм башкару документы конкурс идарәчесенә җибәрелү уңаеннан төгәлләнгән башкару эшләре саны сизелерлек кимегән (2017 елда алар - 319, ә 2016 елда – 583 булган).

Ел дәвамында дүрт ай буе хезмәт хакы буенча бурычлар арту, банкрот дип танылмаган, әмма хезмәт хакы буенча бурычны хәтта суд карары белән дә түләмәгән бурычлы-оешмалар сизелерлек арту, безнең карашча, намуссыз эш бирүчеләргә үзвакытында чаралар күрмәү очраклары артуын дәлилли.

Бу уңайдан хезмәт хакы түләмәү куркынычы булган оешмаларны, шул исәптән, хезмәткәрләрне азат иткән яки тулы

булмаган эш вакыты режимы керткән оешмалар турында халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре биргән мәгълүматлар нигезендә, мәҗбүри түләүләр буенча дәүләт бюджеттан тыш фондларга бурычлары булган предприятиеләр турында Россия Федерациясенең Татарстан Республикасындагы бүлеге һәм дәүләт учреждениесе - Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы төбәк фонды мәгълүматлары, салымнар түләү буенча бурычлары булган предпрятиеләр турында Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе мәгълүматлары буенча ачыклау һәм бурычлы предприятиеләр җитәкчеләре һәм әгәр булса, профсоюз оешмалары белән берлектә эш хакы буенча бурычлар барлыкка килүне кисәтүгә юнәлтелгән оператив чаралар күрү эшен активлаштыру максатка ярашлы булыр иде.

Хезмәт мөнәсәбәтләрен тиешенчә теркәмәү – шикаятьләр буенча тикшерүләр үткәргәндә безнең эштә очраган хокук бозуларның бер төре. Шул ук вакытта хезмәт мөнәсәбәтләрен тиешенчә теркәмәү фактлары коммерциячел структураларда гына түгел, аерым җирле үзидарә органнарында да була.

Республиканың кайбер муниципаль берәмлекләрендә опека һәм попечительлек органнары белгечләренең хезмәт хокуклары гаранатияләрен сакламау проблемасы бар.

Безнең адреска вазифалары муниципаль хезмәткәрләр вазифалары исемлегенә кертелмәгән бер муниципаль районның опека һәм попечительлек секторы хезмәткәрләреннән күмәк мөрәҗәгать керде. Вәкаләтле вәкил опека һәм попечительлек органнарының хезмәт хокукларын бозуны бетерүне сораган заключение җибәрде.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгыннан килгән мәгълүматлар буенча Әлмәт, Югары Ослан, Мамадыш, Питрәч муниципаль районнарында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 1 декабрендә чыккан 843 нче “Татарстан Республикасында балигъ булмаган затларга карата опека һәм попечительлек буенча эшчәнлекне башкару буенча тапшырылган вәкаләтләрне тормышка ашыру Тәртибен раслау турында” карары положениеләрен бозып, бала хокукларын саклау буенча опека һәм

попечительлек органы белгечләре муниципаль хезмәткәрләр булып тормый.

Суд тарафыннан акылга зәгыйфь яки өлешчә акылга зәгыйфь дип табылган балигъ булганнар хокукларын яклау буенча опека һәм попечительлек органнары белгечләре вазифасы муниципаль хезмәткәрләр реестрына кертелмәгән муниципаль районнар саны тагын да күбрәк. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматлары буенча, 2017 ел ахырына республиканың 13 районында (Актаныш, Әлмәт, Әтнә, Балтач, Бөгелмә, Буа, Югары Ослан, Биектау, Кама Тамагы, Мамадыш, Питрәч, Саба, Теләче) суд тарафыннан акылга зәгыйфь яки өлешчә акылга зәгыйфь дип танылган балигъ булган затлар хокукларын яклау буенча опека һәм попечительлек органы белгече вазифасы муниципаль хезмәткәрләр реестрына кертелмәгән.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, хәзерге вакытта әлеге белгечләргә карата тиешле норматив документ юк, алар шулай ук халыкның социаль яктан көчсез төре вәкилләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау белән шөгыльләнсәләр дә.

Бу уңайдан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына суд тарафыннан акылга зәгыйфь яки өлешчә акылга зәгыйфь дип танылган балигъ булган затлар хокукларын яклау буенча опека һәм попечительлек органнары белгечләре муниципаль хезмәткәрләр булырга тиеш, дигән норматив хокукый акт кабул итү мәсьәләсен карау максатка ярашлы булыр иде.

Эшләүче гражданнарның тормышын һәм сәламәтлеген саклау мәсьәләләре социаль-хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә актуаль булып кала.

Татарстан Республикасы Профсоюзлар федерациясе мәгълүматлары буенча республиканың төрле милек формасындагы оешмаларында эш урыннары санитар-гигиена таләпләренә җавап бирмәгән эшчеләр (51 процент яки 467 мең хезмәткәр) саны арта. Шулай итеп, эре яки урта предприятиенең һәр икенче хезмәткәре (һөнәри чирләр артуга кадәр) үз сәламәтлеген куркыныч астына куя. 240 меңгә якын кеше зарарлы җитештерү тирәлегендә эшләвен дәвам

итә. Меңгә якын кеше куркынычсызлык таләпләренә җавап бирмәгән җиһазларда эшли.

Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәт инспекциясенең оператив мәгълүматларына караганда, 2018 елның 1 гыйнварына җитештерүдә авыр нәтиҗәләргә китергән бәхетсезлек очраклары аркасында 140 кеше зыян күргән (2016 елда бу сан – 156.) Шул ук вакытта республиканың кайбер муниципаль районнарында җитештерүдә бәхетсезлек очраклары арту күзәтелә. Җитештерүдә имгәнүләр Азнакай, Алексеевск районнарында 5 тапкыр, Менделеев районында – 4 тапкыр, Тукай һәм Ютазы муниципаль районнарында 2 тапкыр арту, зур борчу тудыра.

Соңгы елларда Татарстан Республикасында җитештерү өлкәсендә үлем очраклары кимү күзәтелә. 2013 елда үлем белән тәмамланган бәхетсезлек очраклары 107 булса, 2017 елда – 44. Җитештерүдә үлүчеләр саны кимү очраклы хәлләр белән генә аңлатылмый. Республикада хезмәтнең куркынычсыз шартларын тәэмин итмәгән эш бирүчеләрне җаваплылыкка тарту буенча гына түгел, ә превентив характердагы чаралар күрелү буенча да системалы эш алып барыла.

Кызганычка каршы, икътисадның аерым өлкәләрендә үлемгә китергән имгәнүләр теркәлә. Үлемгә китергән ике бәхетсезлек очрагы сәламәтлек саклау учреждениеләрендә килеп чыкты (2016 елда алар юк иде). Үлем белән тәмамланган өч бәхетсезлек очрагы агросәнагать тармагында килеп чыкты (2016 елда юк иде).

2016 ел белән чагыштырганда төзелеш тармагы предприятиеләрендә үлемгә китергән имгәнүләр саны артты. (2017 елда - 13, ә 2016 елда – 10). Шул ук вакытта төзелеш эшләрен башкарганда фаҗигале хәлләр хезмәт мөнәсәбәтләре тиешенчә теркәлмәгән кешеләр белән дә килеп чыга. Хезмәт килешүеннән башка төзелештә эшләүче кешеләрнең хезмәтне саклауга социаль җаваплылыгы дәрәҗәсе шактый ким.

Мисал өчен, массакүләм мәгълүмат чараларында Арчада мәктәп төзегәндә төзелеш мәйданчыгында төрле эшләр башкаручы егетнең һәлак булуы киң яктыртылган очрак. Соңыннан судта хезмәткәр

белән хезмәт мөнәсәбәтләрен башкарганда производствода килеп чыккан бәхетсезлек очрагы турында Н-1 формасы буенча акт төзү турында егетнең якын туганының таләбен хәтта “Стройсервис” җәмгыяте төзелеш оешмасы вәкиле танымаган, шулай ук хезмәт мөнәсәбәтләре фактын ачыклау белән бәйле кайбер башка таләпләрне дә танымаган.

Төзелештә һәм башка имгәнү куркынычы зур булган башка тармакларда эшләүче кешеләр белән хезмәт мөнәсәбәтләрен башка мөнәсәбәтләргә “яшергән” оешмаларга дәүләт органнары һәм җирле үзидарәләр органнары тарафыннан аерым контроль кирәк дип саныйбыз. Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 360 нчы маддәсенә төзәтмәләрне исәпкә алып, гражданнар шикаятьләре белән беррәттән, хезмәт мөнәсәбәтләрен теркәүне бозу турындагы дәүләт органнарыннан һәм җирле үзидарәләр органнарыннан кергән мәгълүмат та хезмәт дәүләт инспекторлары планнан тыш тикшерү өчен нигез булып торачак.

Кешенең хезмәт хокукларын яклау эш бирүчеләр ягыннан законнарны саклауга нәтиҗәле контрольне арттыру кирәклеген күздә тота. Контроль превентив та булырга тиеш. Бу аеруча хезмәт законнарын бозуга берничә тапкыр юл куйган эш бирүчеләргә карата актуаль.

## Гражданнарның торакка хокукларын яклау

Татарстан Республикасында торак төзүнең югары темплары саклана. Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы мәгълүматларына караганда, 2017 елда 2408,1 мең квадрат метр торак сафка бастырылган.

Бөек Ватан сугышы ветераннары өчен программа кысаларында 2017 елда 32 ветеран үзенең торак шартларын яхшырткан, хәзерге вакытта ветераннарны торак белән тәэмин итү өчен 12 йорт төзелә, шуларның 4 се төзелеп беткән, 5 йорт төзелеп бетү алдында, 3 се уртача әзерлектә. Аерым төр гражданнарның торак шартларын

яхшыртуга узган ел республика бюджетыннан 159 гаиләгә акча бүлеп бирелгән, 50 күп балалы гаиләгә торак сертификатлары бирелгән.

Торак төзүнең югары темплары республикада гамәлдә булган социаль ипотека программасы исәбенә дә ирешелә, аның кысаларында 90 меңнән артык гаилә үзенең торак шартлары яхшырткан. 2017 елда социаль ипотека программасын тормышка ашыруга каралган 17,6 миллиард сум 8358 фатирлы 178 торак йортны файдалануга тапшырырга гына түгел, 2018 елга 9711 квартирга исәпләнгән 87 йорт төзелешенә нигез салырга да мөмкинлек бирде.

Шуның белән бергә, сафка бастырылган торакның югары күләме турында әйткәндә, шул исәптән, социаль ипотека программасы кысаларында, кайбер күп квартирлы йортларның, шул исәптән, “Салават күпере” торак комплексында төзелә торган кайбер йортларның үзвакытында төзелеп бетмәвен билгеләп үтәргә кирәк.

Икенче проблема – төзелеш сыйфаты. Вәкаләтле вәкил адресына Казан шәһәрендә социаль ипотека программасы буенча төзелгән аерым йортларда, әйтик, Глушко урамының 4 нче, 6 нчы, Актай урамының 7 нче, Адоратский урамының 4а, Сабан урамының 2а йортларында төзелеш сыйфатыннан канәгать булмаган гражданнардан шикаятьләр килү дәвам итә.

2017 елның 20 сентябрендә Татарстан Республикасы Арбитраж судының Казан шәһәренең Глушко урамы 4 нче йортындагы төзелеш кимчелекләрен бетерүне таләп иткән карары законлы көченә керде. Йортта яшәүчеләрнең шикаятьләре “Татарстан Президенты каршындагы дәүләт торак фонды” коммерциячел булмаган оешмасына 2015 елдан ук билгеле. Ләкин оператив чаралар күрелмәгән, суд карары законлы көченә кергәннән соң да инвестор-төзүче буларак Фонд һәм алыштырылган подрядчы оешма арасында төзелеш кимчелекләрен бетерү буенча күләмнәр турында бәхәс 2017 елның декабренә, кассацион шикаять каралганчыга кадәр дәвам итте. Асылда торак йортларда төзелеш дефектларын бетерү буенча чаралар күрелмәде.

Бу уңайдан “Татарстан Президенты каршындагы дәүләт торак фонды” коммерциячел булмаган оешмасына социаль ипотека

программасы буенча торак йортлар төзүне тормышка ашыручы подрядчы оешманы алыштырганда һәм яңа подрядчы оешма белән килешү мөнәсәбәтләре төзегәндә гарантия срогы чорында торак йорттан фпйдалану барышында ачыкланган кимчелекләр булганда, элеккеге подрядчы оешма гаебе белән килеп чыккан төзелеш кимчелекләрен бетерү буенча йөкләмәләрнең конкрет күләмен карау максатка ярашлы булыр иде дип саныйбыз.

Россия Федерациясендә күп балалы гаиләләргә бушлай җир участоклары бирү мәсьәләсе кискен тора.

2017 ел ахырына Казан шәһәрендә генә дә программма эшләү чорында җир участоклары белән 3491 күп балалы гаилә тәэмин ителде. Җир участоклары алырга чиратта торучы гаиләләрнең саны 15 меңнән артык, ә буш булган җир участоклары 3 мең генә, бу республикада җир кишәрлекләренә кытлык булуын күрсәтә. Казан шәһәрендә җир кишәрлекләре кытлыгы - 70 процент (7100), Чаллы шәһәрендә - 58 процент (3500) тәшкил итә.

Аерым очракларда җир кишәрлекләре кытлыгы күп балалы гаиләләргә җир участоклары бирү тәртибен сакламау турында гражданнардан шикаятьләр килүгә китерә.

Безнең адреска Яр Чаллы шәһәрендә яшәүчеләрдән дә җир участокларын бирү срокларын бозу турында шикаятьләр килде.

Тикшерү барышында ике күп балалы гаиләнең 2013 елда җир участогы бирү исемлегенә кертелеп тә, бары 2016 елда гына бер тапкыр җир кишәрлеген сайлау процедурасына чакырылуы ачыкланды. Җир кишәрлекләре исемлеккә соңрак кертелгән башка күп балалы гаиләләргә тәкъдим ителгән.

Татарстан Республикасы Җир кодексында шул билгеләнгән, җир кишәрлеге сайлаудан өч тапкыр баш тартканда яисә җир кишәрлеген сайлау процедурасына өч тапкыр килмәгәндә генә граждан исемлектән төшерелеп калдырыла.

Югарыда күрсәтелгән күп балалы гаиләләр җир кишәрлеген сайлау процедурасына өч тапкыр чакырылырга тиеш иде, моны җирле үзидарә органнары эшләмәгән. Бу уңайдан Вәкаләтле вәкил

бозылган хокук һәм ирекне торгызу максатыннан тиешле заключение җибәрде.

Ятим балаларны, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак йортлар белән тәэмин итү – Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең даими контролендә булган темаларның берсе.

Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның хокукларын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасында ятим балалар өчен 305 торакны милек итеп алу өчен контрактлар төзелгән. 2018 елда торак белән 297 ятимне тәэмин итү күздә тотыла.

Шикаятьләрне анализлау шуны күрсәтә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан гариза бирүчеләрне махсуслашкан торак фондыннан торак белән тәэмин ителергә тиешле ятим балалар исемлегенә кертүдән баш тарту очраклары бар.

Сүз ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан тораклы булып та, федераль һәм республика законнарында каралган нигезләмәләр буенча яшәү өчен яраксыз дип табылган торакка ия затлар белән булган очраклар турында бара.

Вәкаләтле вәкил адресына Бөгелмә шәһәрендә яшәүчедән аны махсуслашкан торак фондыннан ятим бала буларак торак белән тәэмин итмәүләре турында шикаять килде.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы гариза бирүчене торакка мохтаҗ гражданнар исемлегенә кертүдән баш тарткан, сәбәбе итеп аңа муниципаль торак фондында мәйданы тиешледән күбрәк булган бер бүлмәле фатир беркетелгән булуын күрсәткән, гаризаны карау барышында анда беркем дә яшәмәгән булган. Әмма Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы шуны исәпкә алмаган, гариза бирүче белән беррәттән тораклан мөстәкыйль файдалану хокукына гариза бирүченең гаилә әгъзасы булмаган кеше дә ия булган. Махсуслашкан торак фондыннан торак бирүгә каршы булу турында карар чыгарганда

министрлык андый кеше белән социаль найм килешүен өзү турындагы мәгълүматларга ия булмаган.

Яшел Үзән районында яшәүчегә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәйданы тиешле нормадан күбрәк торакта гомуми өлеше булуы уңаеннан торакка мохтаҗ гражданнар исемлегенә кертүдән баш тарткан. Соңрак гариза бирүче, торакны санитар һәм техник кагыйдәләргә һәм нормаларга туры килмәве аркасында яшәү өчен яраксыз дип тану сәбәпле торакка мохтаҗ гражданнар исемлегенә кертелгән. Әмма монда да министрлык карар чыгарганда торакның тагын бер милекчесе гариза бирүченең гаилә әгъзасы булмавын исәпкә алмаган.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, торак милекчеләре булган яки социаль найм килешүе буенча торак алып торган ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм балаларны махсуслашкан торак фондыннан торак белән тәэмин итү турында гаризаларны караганда, һәр очракта 2013 елның 12 гыйнварында дөнья күргән 8 нче “Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак белән тәэмин итү турында” республика Законының 1 маддәсе 4 өлешендәге 1 пункты положениеләрен һәм “Татарстан Республикасында халыкны адреслы социаль яклау турында” Татарстан Республикасы Законының 8 маддәсенә үзгәрешләр кертү турында”гы законны исәпкә алып, гариза бирүче белән беррәттән, торактан мөстәкыйль файдалану хокукына ия затлар булу-булмавын исәпкә алырга тәкъдим итәбез.

Торакка хокукларны тормышка ашыру – гражданнарның уңайлы һәм куркынычсыз торакларда яшәве, ул үз чиратында, капиталь һәм агымдагы ремонт үткәрүне, йорт яны территорияләрен төзекләндерүне, өзлексез күрсәтелгән коммуналь хезмәтләрнең тиешле сыйфатын тәэмин итүне үз эченә ала.

Республикада яшәүчеләр Вәкаләтле вәкилгә торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүне исәпләү, мәгълүматны ачу, торак милекчеләренең гомуми җыелышларын үткәрү тәртибе мәсьәләләре буенча даими мөрәҗәгать итәләр.

Вәкаләтле вәкил адресына килгән мөрәҗәгатьләр темасын киң юнәлешен исәпкә алып, без «Торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсендә җәмәгатьчелек контроле төбәк үзәге» коммерциячел булмаган партнерлыгы, «Татарстан Республикасында күп фатирлы йортлар идарәчеләре оешмалары берлеге» төбәк коммерциячел булмаган партнерлыгы» үзкөйләүле оешмасы белән берлектә республиканың муниципаль районнарында һәм Казан шәһәрендә идарәче компанияләр вәкилләрен чакырып, халык өчен торак-коммуналь хуҗалыгы мәсьәләләре буенча “Хокукый ярдәм көннәре” уздырдык.

2017 елның икенче яртыеллыгында без Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе, кулланучылар хокукларын һәм кешеләр иминлеген яклау өлкәсендә федераль хезмәтнең Татарстан Республикасындагы идарәсе, прокуратура, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәрләре башкарма комитетлары, Татарстан Республикасы Нотариаль палатасы, Татарстан Республикасы Адвокат палатасы, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты, ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар вәкилләре катнашында Казан шәһәрендә, Буа һәм Балык Бистәсе районнарында алты “Хокукый ярдәм көне” үткәрдек.

“Хокукый ярдәм көне” кысаларында яшәүчеләр өчен торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә тематик лекцияләр оештырылды, аларны 1100 кеше тыңлады, шулай ук 147 кешегә бушлай юридик ярдәм күрсәтелде.

Кайбер мөрәҗәгатьләр буенча безнең турыдан туры катнашу кирәк булды.

Әйтик, Вәкаләтле вәкил катнашканнан соң түбәндәге мәсьәләләр уңай хәл ителде: Казан шәһәренең Х.Мәүлетов урамында урнашкан 40 нчы йорт яңы төзекләндерелде, Казан шәһәренең Окольная урамының 3 нче йортында җылыту системасына ремонт ясалды, йортларда яшәүчеләрнең уңай шартларына тәэсир итүче кибетләр эшчәнлегендәге тискәре факторлар бетерелде, Әлмәт шәһәренең Киров урамы 4 нче йортына агымдагы ремонт ясалды.

Республикада яшәүчеләрдән идарәче оешмаларның коммуналь хезмәтләр күрсәтүне туктату яки чикләүгә кагылышлы законсыз гамәлләренә кагылышлы шикаятьләр килә. Төрле хәлләр була. Вакытында түләп барып та коммуналь хезмәтләр күрсәтүне туктату яки чикләү турында карар кабул иткән идарәче оешмаларның законсыз гамәлләреннән якланмаган кешеләр дә бар.

Тикшерү барышында ачыкланган очракларның берсе, коммуналь хезмәтләргә түләмәгән кеше квартирасын сата, ә идарәче оешма яңа милекчегә коммуналь хезмәтләр күрсәтүне туктата, сату-алу килешүе буенча яңа милекче үзенә элеккеге милекченең бурычларын түләү буенча йөкләмәләр алмаса да.

Суд практикасын анализлау шуны күрсәтә, торак милекчеләренә элекке милекчедән җыелган бурычларны түләү буенча таләпләр кую очраклары бер генә түгел.

Бу уңайдан Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә һәм муниципаль торак контроле органнарына, торакны алып торучыларга һәм милекчеләргә торакта элеккеге милекчеләр яшәү чорында барлыкка килгән коммуналь түләүләр буенча бурычлар аркасында (бурычларны түләү буенча йөкләмәләр элеккеге милекче белән сату-алу килешүендә каралган очракларны исәпкә алмаганда) идарәче оешмаларның коммуналь хезмәтләр күрсәтүне туктату яки чикләү буенча гамәлләрен кисәтүгә юнәлтелгән чараларны күрү турындагы мәсьәләне карауны максатка ярашлы булуын тәкъдим итәбез.

Гражданнарның торакка хокукларын тормышка ашыру белән бәйле мәсьәләләр мөһим мәсьәләләрнең берсе булып тора. Гражданнарның торакка хокукларын яклауга һәм торгызуга юнәлтелгән әлеге тәкъдимнәр хакимият органнары тарафыннан яклау табар дип ышанабыз.

**Социаль әһәмиятле учреждениеләрне үзгәртеп кору шартларында кешенең сәламәтлек саклау һәм медицина ярдәменә, белемгә, социаль хезмәт күрсәтүгә хокукларын яклау**

Татарстан Республикасында төрле учреждениеләр эшендә социаль инфраструктураны оптимальләштерүгә юнәлтелгән программалар кабул ителә. Алар арасында медицина һәм социаль хезмәт күрсәтү, мәгариф учреждениеләре аерым урын алып тора.

Сәламәтлек саклау, социаль хезмәт күрсәтү, мәгариф учреждениеләрен үзгәртеп кору процесслары белән бергә, гражданнарның законда билгеләнгән гарантияләр күләмен һәм социаль хокуклары җыелмасын тәэмин итү мөһим.

Безнең фикеребезчә, республиканың аерым муниципаль берәмлекләрендә бала тудыру бүлекләре ябылу һәм медицина учреждениеләренең яшәү урыныннан ерак булуы аркасында гражданнарның медицина хезмәте алуга хокукларын яклау буенча мәсьәлә актуаль булып кала.

2016 елның 1 декабреннән Апас, Югары Ослан, Кайбыч, Кама Тамагы, Яңа Чишмә, Мөслим, Балык Бистәсе, Чирмешән үзәк район хастаханәләрендә 8 бала тудыру бүлеге ябылды. 2017 елның 1 гыйнварыннан тагын өч муниципаль берәмлектә (республиканың Спасс, Минзәлә, Питрәч районнарында ) өч бала тудыру йорты ябылды. Күрсәтелгән муниципаль районнардагы барлык йөкле хатын-кызлар бала тудыру өчен муниципаль ара үзәкләргә җибәрелә. Бала тудыру урыннарының яшәү урыннарыннан шактый еракта булуы хатын-кызларда һәм аларның якыннарында урынлы борчу һәм шөбһә тудырды.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, йөкле, бала тудыручы хатын-кызларны муниципаль ара үзәкләргә илтү өчен үзәк район хастаханәләренә махсус санитар транспорт бүленгән. Бәбиләгән хатын-кызларны муниципаль ара үзәкләрдән беркетелгән авыл территорияләренә җибәрү урта медицина хезмәткәре озатуында санитар автотранспортта тормышка ашырыла.

Ләкин Вәкаләтле вәкилнең йөкле хатын-кызларны, бала тудырган аналарны транспорт белән тәэмин итүне оештыру мәсьәләләре буенча тикшерүләре яңа гына бала тудырган хатын-кызларны муниципаль ара үзәкләрдән яшәү урыннарына озату мәсьәләсе хәл ителмәвен күрсәтте.

Әйтик, "Апас үзәк район хастаханәсе" дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесеннән муниципаль ара үзәкләренә үзәк район хастаханәсе санитар транспортында 72 пациент җибәрелгән. Казан шәһәрендәге республика клиник хастаханәсеннән ананы һәм сабыйны яшәү урынына хастаханәнең санитар транспортында алып кайту бер генә тапкыр булган.

"Питрәч үзәк район хастаханәсе" дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесен тикшерү барышында шул ачыкланды, 2017 елда 259 йөкле хатын-кыз Казан һәм Яшел Үзән шәһәрләрендәге муниципаль ара үзәкләргә үзәк район хастаханәсенең санитар транспортында җибәрелгән. ("Питрәч үзәк район хастаханәсе" дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесендә 8 бала тудыру очрагы теркәлгән). Бала тудыручыны һәм сабыйны, муниципаль ара үзәкләрдән яшәү урыннарына медицина хезмәткәре озатуында илтү бер генә тапкыр, тудырганнан соң сабыйда патология ачыклangannan соң гына булган. Калганнарны туганнары үзләренең шәхси транспортында алып кайткан.

Бәби алып кайтучылар һәм аларның туганнары, "Апас үзәк район хастаханәсе" дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең, "Питрәч үзәк район хастаханәсе" дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең санитар транспорты белән бушлай муниципаль ара үзәкләргә һәм кире яшәү урыннарына озатылуы хакында хәбәрдар булу-булмавы турында мәгълүмат тикшерү барышында бирелмәде.

Хәл Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан йөкле хатын-кызларны медицина хезмәте күрсәтүче медицина оешмаларына транспорт белән озату тәртибе хәзерге көнгә кадәр расланмау белән катлаулана.

Гражданнарның хокуклары бозылуга юл куймау максатыннан Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына тудыру бүлекләре ябылган сәламәтлек саклау учреждениеләренең бала тудырган хатын-кызларны һәм сабыйларны муниципаль ара үзәкләрдән яшәү урыннарына санитар траспортта озатуын оештыру буенча чаралар күрергә кирәк дип саныйбыз.

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә күзәтелә торган социаль хезмәт күрсәтү комплексы үзәкләренең социаль-тернәкләндерү бүлекләрен ябу тенденциясе Вәкаләтле вәкилдә шулай ук борчу тудыра. Соңгы елларда аларның саны шактый кими. 2013 елдан республикада 4 социаль-тернәкләндерү бүлеге ябылган.

Әйтик, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 3 мартында дөнья күргән “Яшел Үзән муниципаль районында Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының “Рәхәт” халыкка социаль хезмәт күрсәтүнең комплексы үзәге” дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе структурасын оптимальләштерү турында” 126нчы карары белән күрсәтелгән социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе структурасында 45 койка-урынга исәпләнгән социаль-тернәкләндерү бүлеге бетерелгән.

Күрсәтелгән бүлекне ябу социаль хезмәтләр алучы гражданнарның канәгатьсезлегенә һәм Татарстан Республикасының төрле дәүләт органнарына, шул исәптән Вәкаләтле вәкил адресына, шулай ук Россия Федерациясе дәүләт органнары адресына күп санлы мөрәҗәгатьләр килүгә китерде.

Шул ук вакытта социаль-тернәкләндерү бүлегендә хезмәт алуга ихтыяҗ шактый зур иде. Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматлары буенча 2016 елда “Яшел Үзән муниципаль районында Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының “Рәхәт” халыкка социаль хезмәт күрсәтүнең комплексы үзәге” дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең социаль-тернәкләндерү бүлегендә 780 кешегә, шуларның күбесе пенсионерлар, социаль хезмәт күрсәтелгән. Хәзер

Яшел Үзән муниципаль районында социаль хезмәтләр алучылар исәбендәге гражданнар социаль хезмәтләр ала алмыйлар, чөнки әлеге муниципаль берәмлегендә социаль хезмәтләр күрсәтүче башка бүлек юк.

2014-2020 елларга "Татарстан Республикасы халыкка хезмәт күрсәтүне үзгәртеп кору һәм үстерү" программасы бурыч сыйфатында халыкка социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә дәүләтнеке булмаган секторны үстерүне билгеләгән иде. Әмма хәзерге вакытта халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсендә эшләп килүче дәүләтнеке булмаган сектор, кызганычка каршы, халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләренең гамәлдәге социаль-тернәкләндерү үзәкләрен тулы күләмдә алыштыра алмый.

Санатор-курорт дәвалануга чират бер генә дистә мең кеше белән исәпләнми, шуңа социаль хезмәтләр алучылар халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләренең социаль-тернәкләндерү бүлекләре мөмкинлекләреннән файдаланалар. Аларда булган койка-урыннар (421) гражданнар ихтыяҗларын канәгатьләндерергә җитәрлек түгел.

Социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрен үзгәртеп кору буенча карарлар кабул итү җәмгыятьтә социаль киеренкелек тудыруын исәпкә алып, Татарстан Республикасы хөкүмәтенә Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендәге социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләренең социаль-тернәкләндерү бүлекләрен саклау мөмкинлеге турындагы мәсьәләне карау максатка ярашлы булыр иде.

Республиканың муниципаль берәмлекләрендә мәгариф оешмаларын үзгәртеп кору сәбәпле гражданнарның белемгә хокукларын тәэмин итү мәсьәләләре дә узган ел Вәкаләтле вәкилнең карау предметы булды.

Гамәлдәге законнарга ярашлы рәвештә муниципаль гомум белем бирү оешмасын үзгәртеп кору яки бетерү балигъ булмаганнарның белем алуга хокукларын бозу дип исәпләнә алмый. Ләкин үзгәртеп кору турында карар кабул иткәнчегә кадәр, муниципаль берәмлек

территориясендә гражданнар белем алу өчен шартлар саклануын һәм конкрет территориядә үсешнең башка шартларының саклануын бәяләү кирәк.

Моннан тыш, федераль һәм республика законнарына ярашлы рәвештә авыл җирлегендә урнашкан муниципаль гомум белем бирү оешмасын үзгәртеп кору яки ябу турында карар шушы авыл җирлегендә яшәүчеләр фикерен исәпкә алмыйча кабул ителергә тиеш түгел.

Федераль законда шулай ук җирле үзидарәләр органнары һәм җирле үзидарәләрнең вазифаи затлары, шулай ук дәүләт хакимияте органнары тарафыннан карарлар кабул иткәндә анда яшәүчеләр фикерен, муниципаль берәмлекнең барлык территориясендә яки аның территориясенең бер өлешендә үткәрелә торган гражданнарны сораштыру юлы белән ачыклау билгеләнгән.

Шуның белән бергә Вәкаләтле вәкил югарыда күрсәтелгән федераль закон таләпләрен үтәмәүдә чагылыш тапкан, билгеләнгән тәртипне бозу фактлары белән очраша.

Әйтик, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитетының норматив хокукый акты белән авыл җирлегендә яшәүчеләр җыены яки халыкны сораштыру урынына авыл җирлегендә яшәүчеләр җыелышын үткәрү билгеләнгән. Соңрак бу положениене Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасы Конституциясенә ярашмый дип таныды.

Үз чиратында, хәтта тиешле норматив хокукый база булганда да мәгариф оешмаларын үзгәртеп кору вакытында әлеге положениеләрне сакламау очраклары бар.

Мәсәлән, Зәй муниципаль районының “Югары Баграж төп гомуми белем бирү мәктәбе” гомум белем бирү оешмасын Зәй муниципаль районының “Сарсаз-Баграж төп гомуми белем бирү мәктәбе”нә кушу юлы белән үзгәртеп кору уңаеннан, Югары Баграж авылы халкының күмәк шикаятен карау барышында шул ачыкланды, авыл җирлегендә яшәүчеләрнең муниципаль гомуми белем бирү оешмасын үзгәртеп коруга кагылышлы фикерен исәпкә алуны

раслаучы документ итеп ата-аналар җыелышы беркетмәсе тәкъдим ителгән.

Ата-аналар җыелышын үткәрү федераль законда каралган тәртипне алыштыра алмый. Шулай итеп, халыкның аларның фикерен белүгә хокуклары бозылган. Шул уңайдан Вәкаләтле вәкил Зәй муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе адресына белем бирү оешмасын үзгәртеп корганчы авыл җирлегендә яшәүчеләр фикерен сораштыру үткәрергә һәм аларның фикерен исәпкә алып, әлеге мәсьәлә буенча ахыргы карар кабул итәргә тәкъдим иткән заключениесен җибәрде.

Гражданнар фикерен сораштыру яки җыен рәвешендә ачыкламыйча, авыл җирлегендә яшәүчеләрнең җыелышы карары рәвешендә ачыклау һәм исәпкә алу гражданнарга мәгариф оешмасын үзгәртәчәкләре турында үз фикерен белдерүгә хокукны тормышка ашырырга мөмкинлек бирми, шулай ук гражданнарга җирле үзидарә органнары тарафыннан сораштыру нәтиҗәләре белән килештерелмәгән карар кабул итү сәбәпләре турында нигезле җавап алуга хокукны гарантияләми.

Вәкаләтле вәкил фикеренчә, авыл җирлегендә яшәүчеләрнең аларның фикерен ачыклауга хокукларын бозу очраклары, кагыйдә буларак, гражданнарның белемгә хокукларын бозу очраклары алга таба булмаска тиеш.

Мәгариф оешмаларын үзгәртеп кору сәбәпле, Вәкаләтле вәкил адресына Яшел Үзән муниципаль районының Васильево бистәсендә мәктәп укучыларын йөртүне оештыру, юлларның начар булуы хакында гражданнардан мөрәҗәгатьләр килде. Җәмәгать транспорты маршруты, мәктәп автобусы булмау аркасында Яшел Үзән муниципаль районының “Советлар Союзы Герое Николай Соболев исемендәге 2 нче номерлы Васильево урта гомуми белем бирү мәктәбе” мәгариф учреждениесе укучылары мәктәпкә кадәр җәяү йөрергә мәҗбүр. Бу уңайдан Вәкаләтле вәкил маршрут челтәрен тикшерү үткәрергә һәм җәмәгать транспорты булдыру кирәклеген ачыклау буенча эш оештырырга, шулай ук юлны ремонтлауны планлаштырырга тәкъдим итте.

Социаль инфраструктура учреждениеләренә реформа үткәрү сәясәте, кешегә лаеклы тормыш һәм иркле үсеш тәэмин итүче шартлар тудыруга юнәлтелгән социаль дәүләт буларак Россия Федерациясендә конституцион положениеләрне кагылгысыз саклап алып барылырга тиеш.

Әлеге положение гаиләгә, аналарга, аталарга һәм балаларга, инвалидларга һәм өлкән гражданнарга дәүләт яклавын тәэмин итү аша, социаль хезмәтләр системасын үстерү, социаль яклауның һәртөрле гарантияләрен билгеләү, сәламәтлек саклауга һәм медицина ярдәменә хокукларны тормышка ашыру аша башкарылырга тиеш.

Бу уңайдан социаль инфраструктура учреждениеләрен оптимальләштерү аларны социаль яклау гарантияләрен, аларның хокукларын һәм ирекләрен саклауда ирешелгән дәрәҗәне киметүгә китерергә тиеш түгел.

## Инвалидларның хокукларын яклау

2017 ел инвалидларның хокукларын яклауда мөһим карарлар кабул итү елы булды.

Россия Федерациясе хөкүмәте 2017 елның 9 ноябрендә медико-социаль экспертиза федераль учреждениеләре тарафыннан сыйфатны бәйсез бәяләү турындагы 1345 нче положениене раслады. Россия Федерациясе хөкүмәтенең 2017 елның 22 ноябрендә дөнья күргән 2599-р нче карары белән сәнагатьнең Россия Федерациясе гражданнары ихтыяҗларын һәм таләпләрен канәгатьләндерүче тернәкләндерү юнәлешендәге товарларны җитештерү буенча көндәшлеккә сәләтле, нык, баланслы тармагын төзү максатында 2025 елга кадәр тернәкләндерү юнәлешендәге сәнагать продукциясен җитештерүне үстерү Стратегиясе расланды. 2017 елның 26 июлендә дөнья күргән "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" федераль законга үзгәрешләр кертү турында" гы 202 нче Федераль законга һәм "Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында" федераль законның 9.1 маддәсенә ярашлы рәвештә, җирле үзидарә органнарына

инвалидларга, физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә физик культураны һәм спортны, адаптив физик культураны һәм адаптив спортны үстерүгә булышлык итү хокукы бирелде.

2017 елның декабрендә Россия Президенты Владимир Путин физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр проблемалары белән шөгыльләнүче профиль иҗтимагый оешмалар һәм һөнәри берлекләр вәкилләре белән очрашты, анда бу өлкәдә мөһим кайбер карарлар яңгырады.

Узган ел Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил инвалид дип танылган гражданнар хокукларын саклау һәм яклауга юнәлтелгән чаралар үткәрде.

Әйтик, Вәкаләтле вәкил башлангычы белән июнь аенда медико-социаль экспертиза һәм техник тернәкләндерү чаралары һәм санатор-курорт путевкалары белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча Идел буе федераль округында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең Координацион советы үткәрелде.

Координацион совет йомгаклары буенча техник тернәкләндерү чараларын сатып алуга дәүләт контрактлары төзү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында, инвалид итеп тану өчен авырулар исемлеген киңәйтү турында, кеше үзе сатып алган техник тернәкләндерү чараларына йөз процент компенсация билгеләү турында һәм граждан бер ел эчендә санатор-курорт дәвасы алмаган очракта, мәстәкыйль рәвештә алынган санатор-курорт путевкасына компенсация билгеләү мәсьәләсен карау турында карарлар кабул ителде.

Тәкъдимнәр Россия Федерациясе хөкүмәтенә һәм Россия Федерациясе Федераль Җыенының Дәүләт Думасына мөрәҗәгать итү өчен Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына җибәрелде.

Дәүләт учреждениесе – Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлеге мәгълүматлары буенча 2017 ел башыннан техник тернәкләндерү чаралары белән тәэмин итүне сорап 78 мең гариза кабул ителгән, шуларның 76 меңнән артыгы тәэмин ителгән, үтәлеш 92 процент

тәшкил итә.

Шул ук вакытта Вәкаләтле вәкил адресына техник тернәкләндерү чаралары бирмәү турында шикаятьләр даими булып тора.

Техник тернәкләндерү чараларына мохтаҗ инвалидларны тулы күләмдә тәэмин итәргә финанс чараларына кытлык булу шартларында, техник тернәкләндерү чарасын үз акчасына алган инвалидка компенсация түләү белән бәйле мәсьәләләр мөһим әһәмияткә ия.

Гамәлдәге законда инвалид мөстәкыйль төстә алган техник тернәкләндерү чарасы яки күрсәтелгән хезмәт өчен компенсация түләү механизмы, аның күләмен билгеләү тәртибе каралган. Компенсация Россия Федерациясе Социаль иминият фондының территориаль органнары тарафыннан түләнә. Дәүләт учреждениесе – Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлеге мәгълүматлары буенча 2017 елда мөстәкыйль рәвештә алынган техник тернәкләндерү чаралары һәм протез-ортопедия әйберләре өчен 2017 елда мөрәҗәгать иткән гражданнарга компенсация түләү өчен 137 миллион сум акча алынган һәм файдаланылган.

Безнеңчә андый компенсациянең якынча күләме турында гражданга ул техник тернәкләндерү чарасы яки хезмәт алганчы билгеле булырга тиеш.

Дәүләт учреждениесе – Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлегенең рәсми сайтында соңгы вакытта сатып алулар аша тормышка ашырылу вакыты буенча билгеләнгән техник тернәкләндерү чаралары һәм хезмәтләрнең бәясе турындагы гражданнарга компенсация күләмен исәпләү өчен кирәкле мәгълүматта 28 төр техник тернәкләндерү чараларының (таяклар, протезлар, колак аппаратлары, туторлар, бандажлар, озатып йөрүче этләр) якынча бәясе турында белешмәләр күрсәтелмәгән. Ягъни әлеге төр техник тернәкләндерү чараларын алган очракта гражданга ул алачак компенсация күләме билгеле түгел.

Шулай ук бирелгән техник тернәкләндерү чаралары сыйфаты белән бәйле проблемалар да бар. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, кайбер төбәкләрдә пилот проекты кысаларында аларны алуның яңа механизмы – гражданнарга үзләренә нәрсә, ничек һәм кемнән сатып алу мөмкинлеге бирә торган электрон сертификат сынала. Әлегә Татарстан Республикасы бу пилот проектында катнашмый.

Хисап чорында Вәкаләтле вәкил дәүләт учреждениесе – Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлеге җитәкчесе урынбасары белән берлектә Казан шәһәренең протез-ортопедия предприятиеләрендә булды. Очрашу ахырында предприятиеләр җитәкчеләре протезларны инвалидның шәхси үзенчәлекләрен һәм ихтыяҗларын исәпкә алып эшләргә кирәклеген әйттеләр. Протезлау вакытында ампутация дәрәҗәсен, яралар, җөйләр барлыгын, йомшак тукымалар торышын, инвалидның гомуми физик хәлен исәпкә алырга кирәк. Белгечләр фикеренчә, әлеге шәхси үзенчәлекләрне исәпкә алмыйча, барлык инвалидларга әзер продукцияне бирү дөрес түгел, бу сәламәтлеккә зыян салырга мөмкин. Үткәрелгән күчмә чара күрсәткәнчә, шактый яхшы җитештерү һәм кадрлар базасы булган безнең предприятиеләр өчен төп проблема – заказлар булмау.

Күрсәтелгән проблема Россия Федерациясе хөкүмәтенең 2017 елның 22 ноябрендә дөнья күргән “Тернәкләндерү юнәлешендәге сәнагать продукциясен үстерү стратегиясен раслау турында”гы 2599-р нчы күрсәтмәсендә дә чагылыш тапкан. Стратегияне тормышка ашыру буенча 2017-2019 елларга эшләр җыелмасы норматив-хокукый көйләү һәм стандартлаштыруны үстерү, җитештерелә торган продукциянең сыйфатын күтәрү, җитештерүне, фәнни-техник эшчәнлекне, инновацияләрне, реабилитация индустриясенең кадрлар потенциалын, сорауны һәм экспортны үстерү, мәгълүмати яклауны күздә тота.

Узган елда Вәкаләтле вәкил тарафыннан инвалидларның уңайлы тирәлеккә: күп квартирлы торак йортларда аз хәрәкәтләнә торган төркемнәр өчен пандуслар кую, физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен спорт объектларының уңайлылыгын оештыруга

кагылышлы хокукларын бозу белән бәйле аерым шикаятьләр буенча чаралар күрелде.

Мәсәлән, Татарстан Республикасының “Халык контроле” дәүләт мәгълүмат системасының “Уңайлы тирәлек” төрендә 2017 елда 338 белдерү бастырылды (шуларның 246 сы хәл ителде, 64 мөрәҗәгать буенча эш планлаштырылган, 25 е дәлилле кире кагылды, 3 се эштә). Мөрәҗәгать итүчеләр махсус лифтлар булмауга, социаль әһәмиятле учреждениеләрдә - хастаханәләрдә, мәктәпләрдә, мәдәният учреждениеләрендә пандуслар юклыкка, җир өсте кичүләрендәге лифтларның эшләмәвенә, инвалидлар һәм башка аз хәрәкәтләнә торган гражданнар төркеме өчен туктап тору (парковка) урыннары булмаудан зарлана. Мондый мөрәҗәгатьләр күбрәк Казан, Яр Чаллы, Әлмәт шәһәрләреннән алына.

Безнең фикеребезчә, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының вакытлыча металл гаражлар куйган инвалидларга җир участокларын арендалау килешүләрен озынайтудан баш тарту турында карар итүе җитди проблема булып тора.

2017 елда инвалидлар исәбендә булган гражданнар Казан шәһәр Думасының 2006 елның 23 августында дөнья күргән 49-11 нче карары гамәлдән чыккан дип табылу сәбәпле җир участогын арендалау килешүен озынайтудан баш тартканлыктан һәм Казан шәһәрендә инвалидлар булган гражданнарга аларның метал гаражларын урнаштыру өчен ташламалы җир участоклары бирүнең расланган тәртибе булмаганлыктан, аларның металл гаражларын сүтүне тормышка ашыру кирәклеге турында кәгазьләр ала башлаган.

Җирле үзидарә органнары “металл гаражлар”дан файдалану төре җир участокларыннан файдалану рөхсәт ителгән төр сыйфатында гамәлдәге законда каралмаган дип белдерә.

“Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында” 1995 елның 24 ноябрендә дөнья күргән 181 нче федераль законга ярашлы рәвештә гаражлар төзү өчен җир бирү зарурлыгы каралган.

Күрсәтелгән очракта металл гаражлар хуҗалары булган инвалидлар төзелеш белән бәйле булмаган максатлар өчен җир участогын арендалау килешүен озынайтуны сорыйлар. Әлеге хәл

аларның аренда килешүен озынайту турындагы үтенеченнән баш тарту өчен нигез булып тора.

Шуның белән бергә җирле үзидарә органнары күрсәтелгән мәсьәләне хәл итүдән читләшергә тиеш түгел дип саныйбыз. Күрсәтелгән 181 нче Федераль законда шулай ук инвалидның техник һәм башка хәрәкәтләнү чарасын кую өчен шәһәр төзелеше нормаларын исәпкә алып, ул яшәгән йорт яныннан урын бирү тиешлеге каралган.

Юл эшчәнлеге, шул исәптән, торак пунктлар чикләрендә парковкалар (туктап тору урыннары) булдыру һәм тәэмин итү җирле әһәмияттәге мәсьәләләргә каравы турында Федераль закон положениеләрен истә тотып, урынны яшәү урынына якын җирдән, нәкъ менә йорт яны территориясеннән бирү мәсьәләсе идарәче компанияләр компетенциясендә генә дигән позиция дөрес түгел дип саныйбыз. Юл эшчәнлеге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын тоту белән генә чикләнми, үзенә күп квартирлы йортларның ишегалды территорияләрен, торак пунктларындагы күп квартирлы йортларның ишегалды территорияләренә керү юлларын капиталь төзекләндерүне дә үз эченә ала.

Инвалид дип танылган затларның хокукларын тормышка ашыру максатларында, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетына инвалид дип танылган затларның металл гаражлары урнашкан җир участокларын арендалау килешүләрен озынайтмаган очракларда, “Инвалидларга уңайлы булган планлаштыру элементлары белән яшәү тирәлеге” турында 35-102-2001 нче кагыйдәләрдәге шәһәр төзелеше нормаларын һәм таләпләрен исәпкә алып, инвалидларның, аларның яшәү урыннарына якын җирдә транспорт чараларын кую урыннарын җиһазлау буенча чаралар күрүен максатка ярашлы булыр дип саныйбыз.

Булган проблемаларны күрсәтеп, шуны билгеләүне дә кирәк дип саныйбыз, инвалидларга карата социаль сәясәт аларны матди яклау ягына гына түгел, инвалидлык профилактикасы, тормыш итү өчен уңайлы тирәлек белән тәэмин итү юнәлешенә таба да камилләшергә тиеш.

## Хәрби хезмәткә чакырылучылар һәм чакырылыш буенча хәрби хезмәткәрләр хокукларын яклау

2017 елда Татарстан Республикасыннан 7500 дән артык хәрби хезмәткә чакырылучы гаскәрләргә җибәрелде, шулардан 2450 се Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре шефлык итә торган хәрби частьларга озатылды.

Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Хәрби комиссары белән берлектә, 2017 елда хәрби хезмәткә чакыру мәсьәләләре буенча гражданнарга консультацияләр бирү эшен, шулай ук “Хокукый белемнәр мәктәбе” күчмә дәресләре кысаларында хокукый агарту буенча чараларны дәвам итте, дәресләрдә республиканың барлык районнарыннан меңнән артык хәрби хезмәткә чакырылучы һәм аларның ата-аналары катнашты.

“Хокукый белемнәр мәктәбе” дәресләре кысаларында хәрби хезмәткә чакырылучыларга һәм аларның ата-аналарына хәрби хезмәт үтүнең нигезләре, хәрби хезмәткәрләрнең хокуклары һәм бурычлары, хәрби хезмәткә чакырылучылар һәм хәрби хезмәткәрләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау механизмнары, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре структурасы, Татарстан Республикасында чакырылышка әзерлек һәм аны оештыру, ашыгыч хәрби хезмәт үтү үзенчәлекләре, гражданнарны хәрби хезмәткә контракт буенча җыю, альтернатив гражданлык хезмәте узу турында аңлатмалар бирелде.

Хәрби хезмәткә чакырганда гражданнар хокукларын яклауны тәэмин итү һәм хокукый ярдәм күрсәтү максатыннан Вәкаләтле вәкил Аппаратында чакырылыш мәсьәләләре буенча “кайнар элемтәләр” оештырылды һәм үткәрелде, аның барышында гражданнар белем алу, гаилә хәле, сәламәтлеге буенча армиягә барудан кичектерелеп тору шартлары һәм шулай ук хәрби хезмәт үтү шартлары, хәрби комиссариатлар һәм чакырылыш комиссияләре эше белән кызыксындылар.

Вәкаләтле вәкилнең һәм аның җәмәгать ярдәмчеләренең хәрби хезмәткә чакырылучыларны хәрби хезмәт үтү урыннарына озата

бару, шул исәптән хәрби эшелоннар составында, хәрби частьларга бару практикасы дәвам иттерелде.

Әйтик, 2017 елда хәрби хезмәткә чакырылучыларны Мәскәү, Түбән Новгород, Оренбург, Свердловск, Саратов, Самара өлкәләренә, шулай ук Краснодар һәм Хабаровск крайларына хәрби хезмәт итү урыннарына озату оештырылды, 19 хәрби часть каралды.

Хезмәт итү шартлары белән “эчтән” танышу, хәрби хезмәткәрләр белән аларның урнашу урыннарында очрашулар Вәкаләтле вәкилгә хәрби коллективларда булган хәлне бәяләргә мөмкинлек бирә. Көнкүрешне һәм хезмәтне оештыру, “швед өстәлләре” системасын кертү, спорт заллары һәм бассейннардан файдалану, казармаларда душ кабинкалары һәм кер юу машиналары булу хәрби хезмәткәрләргә уңайлы атмосферада яшәргә һәм хезмәт итәргә мөмкинлек бирә.

Шуның белән бергә еракка баручы хәрби эшелоннар составында хәрби хезмәткә озату йомгаклары буенча безгә берничә кимчелекләрне дә ачыкларга туры килде, болар – вагоннарда вентиляция начар эшләү, эчә торган су запасы җитмәү, хәрби эшелон озак вакыт туктап тору вакытында бәдрәф бүлмәсенә керү проблемалары. Булган кимчелекләр турында без Татарстан Республикасы Премьер-министры А.В.Песошинга һәм Татарстан Республикасы Хәрби комиссары С.Н.Погодинга хәбәр иттек.

Шулай ук хәрби хезмәткә чакырылучыларга медицина тикшеренүе үткәрү сыйфаты борчу тудыра. Медицина күрсәткечләре буенча хәрби хезмәткә чакырылучыларны озатудан калдыру һәм алга таба дәвалануга җибәрү һәм сәламәтлек торышы буенча нигезсез чакырылган хәрби хезмәткә чакырылучыларның саны арту шушы хакта дәлилли.

Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты мәгълүматларына караганда, 2017 елгы ике чакырылыш кампанияләре чорында 588 кеше медицина күрсәткечләре буенча гаскәрләргә озатудан калдырылган һәм өстәмә тикшерүгә җибәрелгән. 2016 елда андыйларның саны 464 кеше иде. Шулай итеп, медицина

күрсәткечләре буенча гаскәрләргә озатылудан алынучылар саны 2017 елда, 2016 ел белән чагыштырганда 27 процентка артты.

2017 елда 102 кеше сәламәтлек торышы буенча хәрби хезмәткә нигезсез чакырылган дип танылган һәм республиканың Җыелу пунктыннан үзләре килгән шәһәр округлары һәм муниципаль берәмлекләргә озатылган. 2016 елда андыйлар 77 кеше иде. Шулай итеп, сәламәтлек торышы буенча хәрби хезмәткә нигезсез чакырылган һәм республика Җыелу пунктыннан кире өйләренә озатылган гражданнар саны 2017 елда, 2016 ел белән чагыштырганда 32 процентка артты.

Ике чакырылыш кампанияләре чорында сәламәтлек торышы буенча нигезсез хәрби хезмәткә чакырылучылар эре шәһәрләрдән – Казаннан һәм Чаллыдан иде. Сәламәтлек торышы буенча гражданнарны нигезсез хәрби хезмәткә чакыру очраклары зур булмаган муниципаль районнарда да (Аксубай, Биектау, Балтач, Кама Тамагы, Спасс, Кукмара, Ютазы) күзәтелүен билгеләп үтәргә кирәк.

Шул ук вакытта гражданнарны сәламәтлек торышы буенча республика Җыелу пунктыннан кире өйгә озатулары хәрби хезмәткәрләрне хәрби хезмәттән сәламәтлек торышы буенча җибәрелү очракларын бетермәде.

Әйтик, 2017 елда Вәкаләтле вәкилгә Татарстан Республикасыннан хәрби хезмәткә чакырылган хәрби хезмәткәрнең әнисе мөрәҗәгать итте, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты мәгълүматлары буенча 2017 елгы язгы чакырылыш кампаниясенә чакырылганда егет медицина тикшеренүе узган һәм хәрби хезмәткә яраклы дип табылган.

Ләкин хәрби хезмәт үткәндә, 2017 елның ноябрь ахырында, хезмәт итү барышында килеп чыгарга мөмкин булмаган кайбер авырулар буенча хәле кискенләшү аркасында ул хәрби госпитальгә урнаштырылган. 2017 елның декабрендә хәрби-табиблык комиссиясе нәтиҗәләре буенча ул сәламәтлек торышы буенча хәрби хезмәттән җибәрелгән.

Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, Татарстан Республикасы муниципаль районнарындагы һәм шәһәр округларындагы

чакырылыш комиссияләре рәисләренә хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарның медицина тикшеренүе эшен яхшырту буенча чаралар күрүне, һәм кирәк булган очракта, хәрби хезмәткә чакырылучыларны медицина күрсәткечләре буенча гаскәрләргә җибәрүдән калдыру яисә гражданнарны сәламәтлек торышы буенча нигезсез чакыру очракларын азайту максатларында андый гражданнарны өстәмә тикшеренүгә җибәрергә тәкъдим итәбез.

## Миграция мөнәсәбәтләре өлкәсендә кеше хокукларын яклау

Узган 2017 елда Россия Федерациясенең 2025 елга кадәр дәүләт миграция сәясәте Концепциясе икенче этабын тормышка ашыру буенча эш дәвам ителде, һәм гражданнарның аерым төре өчен яшәүгә рөхсәт алганда өстенлекләр булдыруга, Россиягә керүнең яңа тәртибен кертүгә, чит илләрдә яшәүче ватандашларны Россия Федерациясенә ирекле күчерүгә булышлык итү буенча Дәүләт программасында катнашучылар исемлеген киңәйтүгә юнәлтелгән карарлар кабул ителде. Казанда да Үзбәкстан Республикасы илчелеген ачу турында карар кабул ителде.

Шулай ук узган елда, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының чит илләрдә яшәүче ватандашларны ирекле күчерүгә булышлык итү буенча 2017-2018 елларга исәпләнгән программасын раслаган 2017 елның 30 октябрендә дөнья күргән 821 нче карары кабул ителде. Программа өстенлекле мәгариф, сәламәтлек саклау, авыл хуҗалыгы, спорт, мәгълүмат-коммуникацион технологияләр өлкәсендә эшләүче белгечләрне күчерүне, шулай ук бу юнәлешләр буенча укучы студентларны күчерүне күздә тота. Актуаль фәнни һәм технологик проблемалар белән шөгыльләнүче галимнәр һәм белгечләр аерым өстенлеккә ия булачак. Программаны тормышка ашыру республикага 300 ватандашны җәлеп итәргә мөмкинлек бирәчәк.

Программада катнашучыларның саны 300 дип планлаштырганда, чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга Россия Федерациясендә вакытлыча яшәү өчен рөхсәт бирүгә

квоталар саны Татарстан өчен 2018 елда 2017 ел белән чагыштырганда 3500 гә кыскарган һәм 1500 рөхсәтне тәшкил итә. Шуның белән бергә, Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгы мәгълүматлары буенча 2017 елның беренче яртысында вакытлыча яшәүгә рөхсәт бирү турында 2748 карар теркәлгән.

2018 елда вакытлыча яшәүгә рөхсәтләр саны кимү Татарстан Республикасында легаль булмаган төстә яшәүче чит ил гражданнары саны артуга китерергә мөмкин. Шуның белән бергә без, теге яки бу сәбәп буенча безнең ил территориясендә легаль булмаган чит ил гражданнары хокукларын бозуга күп тапкыр игътибарны юнәлттек. (2017 елда Вәкаләтле вәкилгә һәм Вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләренә Россия территориясендә яшәү буенча проблемалары булган 253 кеше мөрәҗәгать итте).

2017 елда Вәкаләтле вәкил Россия Федерациясе территориясендә яшәгән, гражданлыгы булмаган затларның хокукый статусын көйләү белән килеп туган җиңел булмаган хәл уңаеннан Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы Эксперт Советы утырышын оештырды. Бу СССРның элеккеге гражданнарына да, СССР таркалганнан соң төрле сәбәпләр аркасында яңадан оештырылган дәүләтләрнең берсендә дә гражданлык алмаган, хәзерге вакытта Россия Федерациясе территориясендә яшәүче (булучы) аларның балаларына да, хөкем ителү турында карар чыгарылган, кайвакыт Россия территориясендә яшәргә ярамавы турындагы карар булган гражданлыгы булмаган затларга да кагыла.

Эксперт Советы утырышында гражданлыгы булмаганлыктан кайсы да булса дәүләткә чыгарып җибәрү мөмкинлеге булмаган һәм туган иленә кайтару өчен таныклык алырга мөмкинлеге булмаган кайбер гражданнарга кагылышлы мәсьәләләр каралды.

Эксперт Советы йомгаклары буенча тиешле документлар белән гражданcызлык статусын билгеләүнең аерым тәртибен кертү кирәклеге турында, алынмаган хөкем карарына ия гражданлыгы булмаган затларга патент нигезендә хезмәт эшчәнлеген тормышка ашырырга хокук бирү мөмкинлеген карау турында, Россия

Федерациясенең административ хокук бозулар турындагы Кодексына илдән чыгарып җибәрелергә тиешле чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны вакытлыча тоту буенча махсус учреждениеләрдә конкрет булу вакытын билгеләү өлешенә кагылышлы үзгәрешләр кертү турында, ирекне чикләү һәм чыгарып җибәрү турында карарларны үтәү шартларында тоту вакытлары һәм законлылык буенча суд контролен тормышка ашыру турында мөһим карарлар кабул ителде. Тиешле хатлар башкарма хакимиятнең федераль органнарына җибәрелде.

Гражданлыгы булмаган затларның хәлен яхшыртуга Россия Федерациясе Конституция судының 2017 елның 23 маенда булган 14-П номерлы хокукый позициясе булышлык итте, анда положениенең 31.7 һәм 31.9 маддәләре Россия Конституциясенә туры килми дип танылды, “Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында” 2002 елның 25 июлендә дөнья күргән 115 нче федераль законда каралган, Россия Федерациясе чикләреннән мәҗбүри чыгарып җибәрелергә тиешле, махсус учреждениеләрдә гражданлыгы булмаган затларны тоту вакытлары өчен нәтиҗәле суд контролен тәэмин итүгә юнәлтелгән Россия Федерациясенең административ хокук бозулар турындагы Кодексына кичекмәстән үзгәрешләр кертү карар ителде.

Шуның белән бергә, бүген Россия Федерациясе территориясендә ире яки хатыны, балигъ булмаган балалары булган чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны илдән чыгарып җибәрү проблема булып кала бирә.

Вәкаләтле вәкил адресына Үзбәкстан кешесе – граждан У.га карата аны Россия Федерациясе чикләреннән чыгарып җибәрү турында суд карарын юкка чыгаруны сораган күмәк мөрәҗәгать керде.

У. кайсы да булса дәүләтнең гражданлыгына ия түгел, шулай ук аның гражданлыгы булмаган шәхес итеп раслаучы документлары да юк. Россия территориясенә ул 2006 елда әнисе һәм апалары белән килгән, алар инде хәзерге вакытта Россия Федерациясе гражданнары булып саналалар. Ирнең кәләше һәм баласы бар. Үзбәкстанда

мөрәҗәгать итүченең туганнары да, торагы да юк. Ул үзенең Россия Федерациясендә булуын законлаштырырга теләп караган, әмма бу кайбер сәбәпләр аркасында килеп чыкмаган.

Кеше хокукларын һәм төп ирекләрен яклау турында Конвенциянең 8 маддәсен, шулай ук Россия Федерациясе Конституция судының 2013 елның 14 февралендә дөнья күргән 4-П номерлы карарында язылган позицияне исәпкә алып, җаваплылык чарасы мәгънәсе буенча административ җәза максатларына туры килергә тиеш, административ хокук бозулар турында эшне башкару кысаларында күмәк һәм шәхси мәнфәгатьләрнең гадел балансына ирешүне тәэмин итү өчен, Вәкаләтле вәкил Казан шәһәренең Мәскәү район суды карарына протест кертү үтенече белән Татарстан Республикасы прокуратурасы адресына мөрәҗәгать итте.

Прокуратура протест кертте, аны Татарстан Республикасы Югары Суды канәгатьләндереп, административ чыгарып җибәрү булмый калды.

У. белән булган очракта барысы да уңай хәл ителде, ул гаиләсеннән аерылмады. Әмма хәл башкача булырга мөмкин иде. Протест булмаган очракта У. Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны вакытлыча тоту махсус учреждениесендә озак вакыт тотылган булыр иде.

Бу очрак беренче һәм бер генә түгел. Шушы уңайдан Вәкаләтле вәкилнең еллык доклады кысаларында Татарстан Республикасы Югары Судына республиканың район (шәһәр) судларындагы мондый очракларга игътибар итү үтенече белән мөрәҗәгать итәбез.

Узган елда без Россия Федерациясе чикләреннән чыгарып җибәрү рәвешендә административ җаваплылыкка тартканда тагын бер проблема белән очраштык. Ул Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының вакытлыча тоту үзәгенә урнаштырыла торган чит ил гражданнарына аларның балигъ булмаган балаларының кайдалыгын хәбәр итмәүдә чагыла.

Вәкаләтле вәкил адресына ирле-хатынлы Х.лардан мөрәҗәгать керде. Алар икесе дә Таҗикстан Республикасы гражданнары. Казан

шәһәренең район суды карары белән алар 2017 елның мартында алга таба Россия Федерациясе чикләреннән административ чыгарып җибәрү өчен Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының вакытлыча тоту үзәгенә урнаштырылганнар.

Күрсәтелгән гражданнарның дүрт (2003, 2004, 2013, 2014 елларда туган) балигъ булмаган балалары бар. Административ хокук бозу турындагы карарда бу хакта күрсәтелгән.

2017 елның 21 мартында Х. гаиләсенә карата Россия Федерациясе чикләреннән чыгарып җибәрү һәм Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының вакытлыча тоту үзәгенә урнаштыру турында карар кабул ителгәч, дүрт балигъ булмаган бала, ата-анасыз, ялгыз калган.

Ата-аналарын Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының вакытлыча тоту үзәгендә тоту вакытында балаларны төрле приютларга урнаштырганнар. Вәкаләтле вәкил адресына мөрәҗәгать язган вакытка аларның балалары кайда булачагы турында әти кешегә дә, әни кешегә дә, бернинди документ та бирмәгәннәр, балаларның урнашу урынын хәбәр итмәгәннәр.

Вакытында хәлне тикшерү һәм ведомствоара хезмәттәшлек аркасында барлык гаилә әгъзаларын бергәләп Таҗикстан Республикасы территориясенә җибәрү өчен тиешле карарлар кабул ителде.

Бу очракта барысы да яхшы тәмамланды, әмма мондый хәлләргә юл куелырга тиеш түгел. Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгына һәм Татарстан Республикасы буенча Суд приставлары хезмәте идарәсенә мондый очракларга игътибар белән карарга һәм “Бала хокуклары турында” Берләшкән Милләтләр Оешмасы Конвенциясенең 9 маддәсе положениеләреннән файдаланырга кирәк, анда дәүләтләр – конвенциядә катнашучылар баланы ата-анасыннан аермауны тәэмин итә диелә, (бала мәнфәгатьләре хакына аеру кирәклеге очраклары булмаганда).

Россия территориясендә иректән мәхрүм итү урынында булган Таҗикстан Республикасы гражданы аны инвалид итеп тану мәсьәләсе каралганда бик катлаулы хәлдә кала.

Медико-социаль экспертизасы хезмәтләре алу өчен аңа, әлеге хезмәтләрне алганда кирәкле паспортының вакыты чыгу киртә булып торган. Шәхесне раслау турында мөрәҗәгатьләргә Таҗикстан Республикасы Генераль консуллыгыннан җаваплар килмәгән. Ләкин паспорты гамәлдән чыгу вакытына мөрәҗәгать итүче Россия Федерациясе территориясендәге төзәтү учреждениеләрендә җәзаны үтеп бетергән һәм шәхесе үзгәрмәгән.

Ахыр чиктә Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы “Татарстан Республикасы буенча медико-социаль экспертиза баш бюросы” федераль казна учреждениесе тарафыннан мөрәҗәгать итүче шәхесен раслаган документ сыйфатында, аның иске паспортын карау турында карар кабул ителде.

Шуның белән бергә 2017 елның ноябрендә, мөрәҗәгать итүче медико-социаль экспертиза узмыйча, Россия Федерациясенең икенче субъектына оператив дәвалануга китте.

Мондый хәлләргә юл куймас өчен Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә һәм “Татарстан Республикасы буенча медико-социаль экспертиза баш бюросы” федераль казна учреждениесенә иректән мәхрүм итү урыннарында булган һәм җәза үтәү вакытында шәхесен ачыклаучы документы вакыты чыккан чит ил гражданнарын медико-социаль экспертизага җибәрү тәртибен билгеләү максатка ярашлы булыр иде.

## Пенитенциар система учреждениеләрендә тотылучы затлар хокукларын яклау

Федераль законга ярашлы рәвештә мәҗбүри тоту урыннары эшчәнлегенә контрольлек итү функцияләрен тормышка ашырып, Вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты пенитенциар системада кеше хокукларын саклау һәм яклау буенча даими чаралар үткәрә, шул исәптән Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе төзәтү учреждениеләрен һәм тикшерү изоляторларына барып та.

Вәкаләтле вәкил башлангычы буенча кызыксынган органнар һәм җәмәгатьчелек вәкилләре катнашында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны тормышка яраклаштыру мәсьәләләре буенча “түгәрәк өстәл” утырышы үткәрелде.

Мондый эш форматы билгеләнгән өлкәдә булган проблемаларны, шулай ук элеккеге хөкем ителгәннәрне социаль адаптацияләү ысулларын анализларга мөмкинлек бирде.

Шулай ук 2017 ел ахырында Татарстан Республикасы Дәүләт Советында элек хөкем ителгән затларны тормышка яраклаштыруга багышланган киңәшмә үткәрелде, аның нәтиҗәләре буенча Министрлар Кабинетына иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны тормышка яраклаштыру буенча эшче төркем төзергә тәкъдим ителде.

Узган елда җәзаларны үтәү мәсьәләләре буенча хөкем ителгәннәргә “Хокукый ярдәм көне” үткәрү кысаларында төзәтү учреждениеләрендә хөкем ителгәннәрне кабул итү эше дәвам итте. Иректән мәхрүм итү урыннарында җәза үтәүчеләр аларны кызыксындырган сораулар буенча дәүләт органнары, Татарстан Республикасы Адвокат палатасы, Татарстан Республикасы Нотариаль конторасы, иҗтимагый оешмалар вәкилләреннән аңлатмалар алу мөмкинлегенә ия булдылар.

Хөкем ителгәннәр “Хокукый ярдәм көне”ндә мөрәҗәгать итә торган сораулар җыелмасы шактый киң. Медицина ярдәме күрсәтү мәсьәләләрен аерым күрсәтергә кирәк.

Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе төзәтү учреждениеләрендә 2017 елда үткәрелгән тугыз “Хокукый ярдәм көне”ндә медицина ярдәме һәм дәвалауларын сорап 83 кеше мөрәҗәгать итте. Алар арасында Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе төзәтү учреждениеләрендә тар белгеч-табиблар булмау сәбәпле тиешенчә медицина ярдәме күрсәтмәү турында шикаятьләр бар.

Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе тәкъдим иткән мәгълүматларга караганда, 2017 ел дәвамында тар белгеч-табибларның система учреждениеләренә баруы белән

проблема булмаган. Шикләнелүче, гаепләнүче һәм хөкем ителгәннәрне сәламәтлек саклау учреждениеләренә консультацияләр алу, тикшеренү һәм дәвалау өчен алып баруда да киртәләр булмаган. 2017 елда республиканың тикшерү изоляторларына һәм төзәтү учреждениеләренә тар белгеч-табиблар 4286 тапкыр барган, алар үз чиратында, 8328 шикләнелүче, гаепләнүче һәм хөкем ителгән кешегә консультация биргән, тикшерү үткәргән.

Шуның белән бергә медицина тикшеренүе үтүне яки тар профильле табиб-белгечләр дәвалаганны озак көтү иректән мәхрүм итү урыннарында булучыларда үз саулыклары өчен урынлы борчу уята.

Әйтик, 2017 елның 29 августында Вәкаләтле вәкил адресына Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе 2 нче тикшерү изоляторында тотылучыдан электрокардиостимулятор (ЭКС)ның дөрес эшләвен тикшерүне һәм аның эшен коррекцияләүне сораган мөрәҗәгать керде. Йөрәк-кан системасы авыруы аркасында гражданга 2015 елда ЭКС куелган булган һәм ул аппарат эшен бәяләү һәм контрольдә тоту буенча даими төстә кардиолог-аритмолог консультациясенә мохтаҗ булган.

Россия Җәзаларны үтәтү хезмәтенең 16 нчы “медико-санитар часте” сәламәтлек саклау учреждениесе гражданга берничә тапкыр аны стационарга кардиолог-аритмологка алып барабыз дип ышандырган. Көнен билгелиләр, әмма ул соңга таба берничә тапкыр күчерелә. Гражданны ЭКС эшенә бәя бирү һәм контрольлек итү максатыннан консультациягә табиб кардиолог-аритмологка бары 2017 елның 14 декабрендә генә алып барганнар.

Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе учреждениеләрендә тар белгеч-табиблар булмаганлыктан хөкем ителгәннәрне тикшерү яки кабат тикшерү үткәрү өчен медико-социаль экспертизага җибәрү проблемасы борчу уята. Хөкем ителгәннәр төрле медицина, шулай ук дәвалау-профилактика учреждениеләренә, сәламәтлек саклау оешмаларына мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр. Белгечләр кабул итүгә чират булганлыктан, хөкем ителгәннәр авырган чирләр тагын да көчәеп китәргә мөмкин.

Шулай ук республиканың тикшерү изоляторларының чиктән тыш тулы булуын әйтми булмый.

Әйтик, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе мәгълүматлары буенча 2018 елның 1 гыйнварына республиканың кайбер тикшерү изоляторларында урыннар саны буенча лимиттан артып китү фактлары теркәлгән. Аерым алганда, Казан шәһәренең 2 нче тикшерү изоляторында 673 кеше урынына 782 җинаять кылуда шикләнелүче һәм гаепләнүче, Минзәлә шәһәрендә урнашкан 4 нче тикшерү изоляторында 132 кеше урынына 159 шикләнелүче һәм гаепләнүче, Чистай шәһәрендә урнашкан 5 нче тикшерү изоляторында 522 кеше урынына 558 шикләнелүче һәм гаепләнүче тотылган.

Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе чаралар күрүгә карамастан елдан ел республиканың тикшерү изоляторында урыннар булмау проблемасы аеруча кискенләшә.

Әлеге уңайдан Татарстан Республикасы судларына гаепләү карарлары кабул иткәндә икътисадый җинаятьләр кылуда шикләнелүче яки каты авырулар белән авыручы затларны җәмгыятьтән аеру белән бәйле булмаган чаралар билгеләүне тәкъдим итәбез. 2017 ел дәвамында Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе учреждениеләрендә тоту шартлары буенча шикаятьләр килде, болар – кием белән тәэмин итмәүгә, корреспонденцияләр җибәрүгә һәм алуга, хөкем ителгәннәр өчен посылкаларда яки күчтәнәчтә кайбер туклану продуктлары бирү тыелуга кагыла.

Шушы темага кагылышлы кайбер шикаятьләр Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе белән бергәләп эшләү нәтиҗәсендә хәл ителде. Ләкин кайбер очракларда Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе ягыннан аңламау очраклары белән дә очрашырга туры килде.

Әйтик, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе 18 нче төзәтү колониясендә “Хокукый ярдәм көне” үткәрү барышында Вәкаләтле вәкил бәйрәм көнендә эшләгәндә

стройда тезелү вакытында булмаган өчен нигезсез дисциплинар җавапка тарту фактларын ачыклады. Башкача әйткәндә, төзәтү учреждениесе хакимияте хезмәт законнарының, ял вакытын көйләүче положениеләрнең хөкем ителгәннәргә дә кагылуын исәпкә алмаган.

Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе 8 нче төзәтү колониясендә тоту шартларына кагылышлы шикатьләр буенча тикшерүләр үткәргәндә без, озак вакытка исәпләнгән күрешүләрнең вакытын нигезсез кыскарту һәм хөкем ителгәннәр өчен посылкалар һәм күчтәнәчләр кабул итү тәртибен бозу, аерым алганда, посылкаларны һәм күчтәнәчләрне хөкем ителгән кешенең шәхси эшендә күрсәтелгән затлардан да гына алу фактларын ачыкладык. Мондый фактлар шактый иде.

Җинаять-башкару законнары посылкалар, күчтәнәчләр, бандерольләрне хөкем ителгән кешенең шәхси эшендә күрсәтелгән затлардан гына кабул итү тәртибен билгеләми, ә хөкем ителгән кеше ел дәвамында (төзәтү учреждениесе төренә һәм режимына, шулай ук җәза үтәү шартларына бәйле рәвештә) ала торган посылка, күчтәнәч һәм бандерольләрнең санын гына билгели. Биредә хөкем ителүче төзәтү учреждениесе хакимиятенә Россия Федерациясе Җинаять-башкару кодексында посылкаларны алу саны чикләреннән чыкмыйча, посылкаларны һәм күчтәнәчләрне бары аерым затлардан гына кабул итү үтенече белән мөрәҗәгать итә алуын исәпкә алмаганнар.

Ике факт буенча да без Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсенә ачыкланган хокук бозуларны бетерү буенча тиешле һәм кирәкле чараларны күрүне тәкъдим иткән мөрәҗәгать җибәрдек. Ләкин Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсендә безнең тәкъдимнәрне исәпкә алмадылар. Ахыр чиктә әлеге хокук бозулар без прокуратура органнарына мөрәҗәгать иткәч прокурор күргән чаралардан соң бетерелде.

Мондый хәлләргә юл куймас өчен Вәкаләтле вәкил иректән мәхрүм итү урыннарында булган затларга карата хезмәт турындагы законнарның ял һәм бәйрәм көннәрендә ялга кагылышлы таләпләрен туры күләмдә саклау кирәклегенә, шулай ук хөкем ителгәннәр өчен

посылкалар һәм бандерольләр алганда җинаять-башкару законнарын үтәүгә һәм хөкем ителгәннәрнең туганнары белән озакка сузылган күрешүләр өчен билгеләнгән вакытны үтәүне тәэмин итүгә игътибарны юнәлтүне максатка ярашлы дип саный.

Закон бозган һәм шуның нәтиҗәсендә иректән мәхрүм итү белән бәйле җәзаларга тартылган затларга гуманлы караш заманча җәмгыятькә хас булырга тиеш. Мәҗбүри тору урыннарында булган затларның хокукларын чикләү законда билгеләнгән чикләрдән чыкмаска тиеш.

## Йомгак

Докладта кеше хокукларын яклау һәм тәэмин итү проблемаларыннан чыгып, Вәкаләтле вәкил түбәндәге нәтиҗәләргә туктала.

Хезмәт хокукый мөнәсәбәтләре өлкәсендә элеккечә үк хезмәт хакын үзвакытында түләмәү проблемасы кискен тора. Аның масштабларын киметү өчен хакимият органнары һәм җирле үзидарәләр органнары тыгыз хезмәттәшлектә эшләргә тиеш. Бу хезмәттәшлектә җитештерүдә имгәнүләрне киметүгә һәм эш бирүчеләрнең хезмәткәрләр белән хезмәт мөнәсәбәтләрен тиешенчә теркәү өлешендә хезмәт законнары таләпләрен саклавына юнәлтелгән системалы эш алып баруы бик мөһим булып кала.

Татарстан Республикасында торак төзүнең югары темплары сакланса да, гражданнарның торакка хокукларын саклау һәм тәэмин итү белән бәйле хәл ителмәгән аерым проблемалар кала.

Социаль ипотека программасы буенча төзелгән, кайбер очракларда гарантия вакыты чорында төзелеш кимчелекләре ачыкланган торак йортларда яшәүче гражданнарны уңайлы һәм имин шартлар белән тәэмин итү буенча оператив чаралар кабул итәргә кирәк. Махсуслашкан торак биналарының найм килешүләре буенча махсуслашкан торак фондыннан торак алырга хокукы булган ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның

торакка хокукларын тормышка ашыруга нык игътибар бирелергә тиеш.

Торак алып торучылар һәм милекчеләр, элеккеге торак алып торучыларның һәм милекчеләрнең коммуналь хезмәтләргә түләү буенча бурычлары җыелган очракларда (элеккеге милекче белән торакны сату-алу килешүендә каралган бурычларны түләү буенча йөкләмә алган очракларны исәпләмәгәндә), суд һәм судтан тыш тәртиптә коммуналь хезмәтләрне туктату яки чикләүдән сакланган булырга тиеш.

Сәламәтлек саклау, социаль хезмәт күрсәтү һәм мәгариф учреждениеләрен үзгәртеп кору белән беррәттән, гражданнарның социаль хокуклары җыелмасын һәм законда билгеләнгән гарантияләр күләмен тәэмин итү мөһим.

Республиканың кайбер муниципаль берәмлекләрендә тудыру бүлекләре ябылу һәм медицина учреждениеләренең яшәү урыннарыннан ерак булуы сәбәпле медицина ярдәме алуга гражданнарның хокукларын саклау белән бәйле аерым мәсьәләләрне хәл итү актуаль булып кала. Халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрен, мәгариф оешмаларын үзгәртеп кору яки ябу процесслары гражданнарның социаль яклану дәрәҗәсен киметүгә китерергә тиеш түгел.

Нәтиҗәле социаль сәясәт инвалидларны җәмгыятьтә тулы тормыш белән яшәү өчен башка гражданнар белән тигез мөмкинлекләр тәэмин итүдән башка мөмкин түгел. Техник тернәкләндерү чараларына мохтаҗ инвалидларны тулы күләмдә тәэмин итүгә җитәрлек финанс чаралары булмау шартларында, техник тернәкләндерү чарасын үз акчасына алган инвалидка компенсация түләү белән бәйле мәсьәләләр мөһим әһәмияткә ия.

Татарстанның гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү буенча алдынгы позицияләре хәрби хезмәткә чакырылучыларга медицина тикшеренүләре үткәрү буенча сыйфатлы эш белән аерылып торырга тиеш.

Пенитенциар система учреждениеләрендә медицина ярдәме күрсәтү һәм башка шартларны булдыру, иректән мәхрүм итү

урыныннан азат ителгәннәрне тормышка яраклаштыру актуаль мәсьәләләр булып кала.

Югарыда әйтелгәннәрне исәпкә алып, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен саклауны тәэмин итү һәм көчәйтү максатыннан, Вәкаләтле вәкил дәүләт органнарына, җирле үзидарәләр органнарына һәм вазифадагы затларга түбәндәге чараларны күрергә тәкъдим итә.

1. Хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә кеше хокукларын тормышка ашыру максатыннан:

1.1.Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына судта акылга зәгыйфь яисә өлешчә акылга зәгыйфь дип танылган балигъ булган затларның хокукларын яклау буенча опека һәм попечительлек органы белгечләре муниципаль белгечләр булырга тиеш дигән норматив хокукый акт кабул итү мәсьәләсен карарга.

1.2. Хезмәт законнарын саклауга күзәтчелекне тормышка ашыручы дәүләт органнарына республиканың Әлмәт, Югары Ослан, Мамадыш, Питрәч муниципаль районнарында бала хокукларын яклау буенча опека һәм попечительлек органы белгечләрен муниципаль хезмәткәрләр вазифалары исемлегенә кертүгә юнәлтелгән көйләү чаралары кабул итү турында мәсьәләне карарга.

1.3. Җирле үзидарә органнарына:

тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча ведомствоара комиссияләр кысаларында эш хакын түләмәү куркынычы булган оешмаларны ачыклау һәм эш хакы буенча бурычлар җыелуны кисәтүгә юнәлтелгән оператив чаралар кабул итү буенча эшне активлаштырырга;

тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча ведомствоара комиссияләр һәм хезмәтне саклау буенча координацион советлар кысаларында төзелеш эшчәнлеге алып барган, хезмәт килешүе теркәүдән читләшкән яки граждан-хокукый килешүләр төзүче оешмалар турында планнан тыш тикшерүләр үткәрү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә мәгълүматлар тапшыру эшен оештырырга.

2. Гражданнарның торакка хокукларын тормышка ашыру максатыннан:

2.1. “Татарстан Президенты каршындагы дәүләт торак фонды” коммерциячел булмаган оешмасына социаль ипотека программасы буенча торак йортлар төзүне тормышка ашыручы подрядчы оешманы алыштырганда һәм яңа подрядчы оешма белән килешү мөнәсәбәтләре төзегәндә гарантия вакыты чорында торак йорттан файдалану барышында ачыкланган кимчелекләр булганда, элеккеге подрядчы оешма гаебе белән килеп чыккан төзелеш кимчелекләрен бетерү буенча йөкләмәләрнең конкрет күләмен карарга.

2.2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, торак милекчеләре булган яки социаль найм килешүе буенча торак алып торган ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм балаларны махсуслашкан торак фондыннан торак белән тәэмин итү турында гаризаларны караганда, һәр очракта 2013 елның 12 гыйнварында дөнья күргән 8 нче “Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән калган балаларны торак белән тәэмин итү турында” республика Законының 1 маддәсе 4 өлешендәге 1 пункты положениеләрен һәм “Татарстан Республикасында халыкны адреслы социаль яклау турында” Татарстан Республикасы Законының 8 маддәсенә үзгәрешләр кертү турында”гы законны исәпкә алып, гариза бирүче белән беррәттән, торактан мөстәкыйль файдалану хокукына ия затлар булу-булмавын исәпкә алырга.

2.3. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенә һәм муниципаль торак контроле органнарына, торакны алып торучыларга һәм милекчеләргә торакта элеккеге милекчеләр яшәү чорында барлыкка килгән коммуналь түләүләр буенча бурычлар аркасында (бурычларны түләү буенча йөкләмәләр элеккеге милекче белән сату-алу килешүендә каралган очракларны исәпкә алмаганда) идарәче оешмаларның коммуналь хезмәтләр күрсәтүне туктату яки чикләү буенча гамәлләрен кисәтүгә юнәлтелгән чараларны күрү мәсьәләсен карарга.

3. Аерым төр гражданнарның сзламәтлек саклауга һәм медицина ярдәменә хокукларын тормышка ашыру максатыннан, Татарстан

Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына муниципаль берәмлекләрнең тудыру бүлекләре ябылган сәламәтлек саклау учреждениеләренең бала тудырган хатын-кызларны (алар риза булган очракта) һәм сабыйларны муниципаль ара үзәкләрдән яшәү урыннарына санитар траспортта озатуын оештыру, аларга мондый мөмкинлек булу турында мәгълүмат бирү буенча чаралар күрергә кирәк.

4. Аерым төр гражданнарның социаль хезмәт күрсәтүгә хокукларын тормышка ашыру максатыннан Татарстан Республикасы хөкүмәтенә Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләренең социаль-тернәкләндерү бүлекләре санын саклау мөмкинлеге турындагы мәсьәләне карарга.

5. Гражданнарның белем алуга хокукларын тормышка ашыру максатыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетлары җитәкчеләренә авыл җирлегендә урнашкан муниципаль гомуми белем бирү оешмасын үзгәртеп кору яки ябу турында карар кабул итү очракларында гражданнар җыеннары үткәрү яки аларны сораштыру юлы белән авыл җирлегендә яшәүчеләр фикерен исәпкә алуга юнәлтелгән чаралар үткәрүне тәэмин итәргә.

6. Инвалидларның хокукларын тәэмин итү һәм яклау максатыннан:

6.1. Дәүләт учреждениесенә – Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстандагы төбәк бүлегенә рәсми сайтта техник тернәкләндерү чараларын сатып алуны һәм хезмәтләр күрсәтүне тормышка ашыру вакыты нәтиҗәләре буенча билгеләнгән барлык техник тернәкләндерү чаралары һәм хезмәтләрнең бәясе турында мәгълүмат урнаштырырга.

6.2. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетына инвалид дип танылган затларның металл гаражлары урнашкан җир участокларын арендалау килешүләрен озынайтмаган очракларда, шәһәр төзелеше нормаларын исәпкә алып, инвалидларның, аларның яшәү урыннарына якын җирдә транспорт чараларын кую урыннарын җиһазлау буенча чаралар күрергә.

7. Хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле яшь егетләрнең хокукларын яклау максатыннан муниципаль районнардагы һәм шәһәр округларындагы чакырылыш комиссияләре рәисләренә хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарга сыйфатлы медицина тикшеренүен оештыруга юнәлтелгән чаралар күрергә.

8. Мәҗбүри тоту урыннарында тотылучы затларның хокукларын яклау максатыннан:

Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсенә:

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы “Татарстан Республикасы буенча медико-социаль экспертиза баш бюросы” белән берлектә иректән мәхрүм итү урыннарында булган һәм җәза үтәү чорында вакыты чыккан шәхесен ачыклаучы документы булган чит ил гражданнарын медико-социаль экспертизага җибәрү буенча хезмәттәшлек тәртибен билгеләргә;

Татарстан Республикасы төзәтү учреждениеләре җитәкчеләренә хөкем ителгәннәргә аларның туганнары булмаган затлардан тоткарлыксыз посылкалар алуны тыюга юл куймаска.

С.Х. Сабурская,
Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил
Казан, февраль, 2018 ел

# ДОКЛАД УПОЛНОМОЧЕННОГО ПО ПРАВАМ ЧЕЛОВЕКА В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН

# О СОБЛЮДЕНИИ ПРАВ И СВОБОД ЧЕЛОВЕКА И ГРАЖДАНИНА В РСЕПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН В 2017 ГОДУ

Аппарат Уполномоченного по правам человека в Республике Татарстан
Адрес: 420015, г. Казань, ул. К. Маркса, 61
Тел./факс: (843) 236-41-80
E-mail: tat.ombudsman@tatar.ru
www.upch.tatarstan.ru

Отпечатано в ГК «ШиП»
Тираж 250 экз.
420080, г. Казань, ул. Декабристов, 185/47
Тел.: (843) 555-11-11

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА КЕШЕ ХОКУКЛАРЫ БУЕНЧА ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛ ДОКЛАДЫ

# 2017 ЕЛДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА КЕШЕ ҺӘМ ГРАЖДАННЫҢ ХОКУКЛАРЫН ҺӘМ ИРЕКЛӘРЕН САКЛАУ ТУРЫНДА

Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты
Адрес: 420015, Казань ш., К. Маркс ур., 61
Тел./факс: (843) 236-41-80
E-mail: tat.ombudsman@tatar.ru
www.upch.tatarstan.ru

ГК «ШиП» нәшер ителде.
Тираж 250 данә.
420095, Казань ш., Декабристов ур., 185/47
Тел.: (843) 555-11-11